www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 43 (1408) 3 ноябрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

12

Төньяк Боз океанына хәтле хезмәткә барып җиткән милләттәшләребез тырышлыклары, тугрылыклары белән анда да хөрмәт казана.

16

Атаклы театраль нәсел вәкиле Гәүһәр Камалова тамашачы хәтеренә бик сылу, туры сүзле, гадел артист булып кереп калды.

18

Татарстанның тау ягы төбәге авылларының үткәнендә ак таплар, буталчыклар әле бик күп дип саный туган ягының тарихын өйрәнгән В. Данилов.

Тормыш үзе куйган сорауларга Бергәләшеп эзлик җавабын да!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Казанда узган Мөселман мәдәнияте яшьләр фестивалендә Индонезия, Гамбия, Гыйрак, Казахстан, Пакьстан, Мисыр, Тунис, Бангладеш һ.б. илләрнең вәкилләре катнашты.

● Балтач районының Бөрбаш авылында төзекләндерүдән соң тантаналы рәвештә мәдәният йорты ачылды.

● Чувашиянең Комсомол районы Тукай авылы урта мәктәбендә Татарстан Дәүләт Советы делегациясе катнашында Татар мәгърифәте көненә багышланган чаралар узды.

● Башкортстанның Әбҗәлил районы Баим авылында реставрациядән соң 112 нче башкорт кавалерия дивизиясенең командиры Миңнегали Шәймөратовка һәйкәл ачылды.

● Казанның Бауман урамындагы «Китап-club» ресторанында юмор остасы Алмаз Хәмзинның «Биш татар» китабының тәкъдим итү кичәсе узды.

● Бүген Әлмәтнең Тельман урамында Габдулла Тукай исемендәге яңа модель балалар китапханәсе эшли башлый.

● Ульяновск шәһәрендә татар милли хәрәкәтенең чишмә башында торган актив җәмәгать эшлеклесе, танылган гармунчы Иршат Аббазов вафат булды.

● 8 ноябрьдә Казан халкы һәм башкала кунаклары Казан Кремленең музейларын һәм күргәзмә залларын бушлай карый алачак.

● Шагыйрь һәм балалар язучысы Ленар Шәехнең татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән «Алдамыйм!» («Я не лгу!») китабы С.Маршак исемендәге Бөтенроссия әдәби премиясенең лонг-листына кергән.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ, язучы:

«Без әдәбият тарихын белмибез. Мәскәү, Мордовия, Нижгар тирәләрендә татар әдәбияты турында сөйләшсәң, Габдулла Тукай белән Муса Җәлилне генә беләләр. Әйтерсең башка әдәбият юк безнең. Үзебез дә шушы хатаны кабатлыйбыз. Тукай бит үзен Габделҗәббар Кандалый укучысы итеп санаган. Көнчыгыш классикасы дәрәҗәсендәге шушы шагыйрьне, кызганыч, бездә күрсәтә белү, пропагандалау юк. Теле дә аңлашылмый дип кул селтәргә өйрәндек».

СЫНАМЫШЛАР

4 ноябрьдән беренче кыраулар башлана, гадәттә, бу көнне коеп яңгыр ява ● 5 ноябрьдә кар яки вак боз яву кышның 22 ноябрьдән башланачагын күрсәтә ● 8 ноябрьдә салкын һәм карлы булса, яз соң киләчәк, һәм киресенчә. Бу көнне кар яуса, Пасхада да кар явачак ● Ноябрь кар өрә – галәмгә ашлык китерә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 53 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 59 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 06 минут.** Алдагы сигез көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **11 ноябрьдә 8 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

4 ноябрь – язучы һәм тәнкыйтьче Гали Мөхәммәтшакир улы Рәхимнең (Габдерәхимов) тууына 130 ел (1892–1943).

5 ноябрь – актёр, режиссёр, Татарстанның атказанган артисты Бари Шиһабетдин улы Тархановның (Гаффаров) тууына 130 ел (1892–1933).

6 ноябрь – Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итүгә 30 ел (1992).

10 ноябрь – шагыйрь Бәхтияр Гомәр улы Мирзановның тууына 120 ел (1902-1941);

– журналист, җәмәгать эшлеклесе Миншәех Харис улы Зәбировның тууына 90 ел (1932–2009);

– язучы, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллинга 90 яшь (1932);

– язучы Габдулла Мәхмүт улы Вафинга 55 яшь (1967).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(1-8 ноябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл ахир аеның 9 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Җыр һәм бию ансамбле бинасы аяныч хәлдә

«Еламаган балага имезлек каптырмыйлар», – диләр татарда. Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең беркайчан да зарланып йөргәнен хәтерләмим. Ә бит «республиканың визит карточкасы» булган коллективның яшәү шартлары бер дә күңелле түгел икән ләбаса. Теманы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларының берсендә депутат, Татарстанның халык артисты Рамил Төхфәтуллин күтәрде.

Рамил Төхфәтуллин: «Быел Татарстанның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешуга 85 ел тула. Үткән атнада аларның бинасында булдым, озак сөйләшеп утырдык. Без ансамбльнең дистәләрчә еллар дәвамында «республика бренды» булуын онытмыйк. Кызганыч, брендның формасы һәм эчтәлеге аерыла. Алар эшләгән бина коточкыч хәлдә. Ансамбльнең ул бинада эшләү мөмкинлеге юк. Әйтик, 40 бала 2х3 метрлы бүлмәдә кием алыштыра. Бию залларында диварлардан штукатурка коела.

Кемнең дә булса ул бинада булганы бармы? Аңа реконструкция мәсьәләсе яки ансамбльгә бина табу мәсьәләсе караламы? Бина мәсьәләсе – бюджетка салынганмы? Брендны югалтуы бик җиңел...»

Утырышта катнашкан Татарстанның мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов: «Без бу проблеманы беләбез. Ансамбльне күчерү мәсьәләләре дә каралды. Проект документациясенә акча да бүлеп бирелгән иде», – дип җавап бирде.

Тарихи белешмә: Ансамбль «Арианов-Тельпугов йорты» дип аталган бинада – республика дәрәҗәсендәге әһәмиятле иң мәдәни мирас объектында урнашкан. Островский урамындагы 2 нче санлы бина – бу урамдагы сәүдәгәр йортларының берсе. Тарихи белешмәләр бу йортның, бер сәүдәгәрдән икенчесенә сатылып, берничә хуҗасы булуын раслый. Мәдәни мирас объектының исеме дә шуны күрсәтә: сәүдәгәр Арианов аны отставкадагы капитан Тельпуговтан сатып алган. Аннан алда да берничә хуҗасы булган. Һәр хуҗа үзенчә үзгәртеп, биредә ампир, эклектика һәм модерн стильләре кушылган. Совет чорында биредә коммуналка, берара НКВД да урнашкан булган.

Объект 3 катлы бинаны тәшкил итә. Гомуми мәйданы – 1280 кв.м. XIX гасыр башларында салынган булырга тиеш. Бина Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең репетицияләре һәм административ-хуҗалык эшчәнлеге өчен тәгаенләнгән. Бинага соңгы тапкыр 1996-1999 елларда ремонт ясалган. 2019 елгы экспертиза нәтиҗәләре буенча, подвал һәм түбә авария хәлендә. Бина ишегалдына һәм андагы боксларга ремонт сорала.

Дәүләт җыр һәм бию ансамбле директоры Юрий Жуков һәм сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов бина буйлап экскурсия үткәрергә ризалашты. Безгә бинаның ярымподвал өлешендәге костюм бүлмәләреннән башлап чормага кадәр карап чыгарга мөмкинлек тудырылды. Дивардагы ярыкларны да, су үтеп дымланган стеналарны, черегән калайларны, иске рамнар бүселеп чыгып төшкәнгә куела башлаган, әмма урнаштырылып бетмәгән рамнарны да күрдек. Кеп-кечкенә грим бүлмәләре дә, архив язмалары саклanган эт оясы кадәр китапханә дә бар. Аптыраганнан чорманың бер почмагына ясалган тавыш яздыру студиясенә дә кердек. Тегү цехына күз салдык, костюмнар, реквизитлар саклanган ярымподвал катына да төштек.

Ремонтка кадәр бу бинада коммуналка булган, бер ишектән биредә яшәүчеләр йөрсә, икенчесеннән – артистлар. «Шулай «күңелле» яшәгән чаклар бар иде», – дип көлә өлкән буын. Әкренләп, кешеләрне күчереп бетергәннәр. Бинага 90 нчы елларда ремонт ясалган. 1998 елдан бирле коллектив биредә эшли.

Коллектив, беркемне борчымыйча, үзбелдеге белән киңәергә дә тырышып караган. Чорманы да бүлмәләр буларак куллану идеясе булган. Әйтик, административ өскә күтәрсәләр, 2 һәм 3 нче катларны ижат өчен генә калдыру мөмкинлеге булыр иде. Бина архитектура ядкәре булгач, ярамый, дигәннәр. Чөнки бинаның документациясендә чорманы куллану каралмаган.

А.Хәмитов: «Дөрес аңлагыз, без зарланып еламыйбыз. Сезгә беренче тапкыр «скелеты»бызны ачып күрсәттек, моңарчы гел елмаеп тордык».

Ю.Жуков: «Әмма гел алай була алмый, чөнки мин «түбә ишелеп төшәр» дип курка башладым. Биредә хезмәт куркынычсызлыгын саклау таләпләренә җавап биреп булмый башлады».

Мөгаен, бу бина ансамбль өчен үз бурычын үтәгәндер инде. Коллектив алдына куелган зур таләпләр турында сөйләшсәк, репетиция мәйданчыкларының киңәюе кирәк. Бу бинадан зарланасым килми, ләкин биредә берничек тә киңәеп булмаганлыгы күренеп тора.

А.Хәмитов: «Хәзерге вакытта: «Безгә яңа бина бирегез!» – дип кычкыру да яхшы түгел. Әмма ул барыбер булачак. Анда ансамбльнең музее да, зур студия дә булачак. Студиягә 50 түгел, 500 кеше йөриячәк. Ветеран артистларыбыз анда укыта алыр иде. Безнең концертлар бирерлек, фестивальләр оештырырлык залыбыз булыр. Безгә кунакка танылган коллективлар килер...»

– Сезнең хыял турында "хыяллану файдалы", диделәрме?

– Хыялланунның зыяны юк, хыялланмау начар, диләр. Шаярмыйча гына әйткәндә, безгә ярдәм юк, дип зарлана алмыйм. Ярдәм бар. Ләкин без соң чиккә килеп җиттек. Алга таба биредә уникаль костюмнар өчен куркыныч.

Ю.Жуков: «Проблема бүген килеп чыкмады. Хатлар 2016 елдан бирле языла. Министрлык безне ишетми, дия алмыйбыз. Министр барысын да белә. Ансамбль дәүләт планын үти, концерт-гастроль эшчәнлеген алып барабыз. Ягъни бары да яхшы кебек, шунлыктан парадокс килеп чыга... Ә безгә үсәргә, киңәергә, моның өчен мөмкинлекләр кирәк. Әмма без хәзер алга бара алмыйбыз, кысан мәйданда өерелешеп торабыз кебек».

А.Хәмитов: «Хәзер бернәрсә дә эшләмәсәк, алга таба хәлләребез тагын да начарланачак. Түбәне булса да япсыннар иде. 1937 елдан бирле түзгәнне, тагын бераз түзәр идек әле... Кая ашыгыйк? Безгә, түбә япмыйбыз, дип әйткән кеше юк. Ләкин кәгазь эше озак йөри».

Әйе, ансамбльнең нинди шартларда эшләвен җитәкчелек яхшы белә. Ансамбль җитәкчелеге зур гына өем рәсми кәгазьләр күрсәтә – болар ансамбль директоры Ю.Жуков белән төрле җитәкчеләр арасындагы хатлар. 2015 елдан башлап, хатлар элеккеге мәдәният министры А.Сибагатуллинга, урынбасары С.Персовага, ТР Дәүләт Советы рәисе Ф.Мөхәммәтшинга, мәдәният министры И.Әюповага һ.б.га язылган. Редакция карамагындагы хатларның кайбер юллары:

2019 ел. «Һава шартларының начараюы түбәнең ишелеп төшүенә китерергә мөмкин».

2021 ел. «Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле бинасына ремонт-реставрация эшләре үткәрү өчен проект-смета документациясе әзерләнгәннән соң 2ел вакыт узды. Бу вакыт эчендә проект авторлары белән бергә бинага мониторинг ясау ихтыяҗы туды. Комиссия түбәндәгеләрне күрде: 1. Бинаның подвалында күгәрек һәм гөмбәчек мәйданы арткан. Грунт сулары дымлылыкны арттырган. Фундамент утырган. Шуның аркасында күгәрек өске катларга күтәрелә, ә бу – ансамбль коллективының сәламәтлегенә куркыныч тудырырга мөмкин. 2. Бинаның фундаменты утыру бинаның эчке һәм тышкы ягында ярыклар барлыкка китергән. 3. Түбә калае черү чардакның дымлануына китерә, түшәмгә су үтә. 4. Бинаның утыруы аркасында, тәрәзә рамнары тротуарга чыгып төшә...»

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидеген
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Янусың бер читтә торсын

Бәндә хатадан хали түгел, ди мәкаль. Әйе, чыннан да, хаталану адәми затка хас нәрсә һәм әхлакый яктан ул әллә ни кимчелек саналмый да. Тик кешеләр арасында, аңлы рәвештә явызлык кылып, яманны яхшы итеп күрсәтергә тырыша торган монафикъ затлар да шакый. Тыштан яхшы булып күренеп, асылда әшәкелек кылучы андыйларны, борынгы Рим алласы (сүз ике йөзле – бер як йөзе яшь, капма-каршы йөзе карт итеп сурәтләнгән Рим алласы Янус турында бара) исеме белән символлаштырып, «икейөзле Янус» дип тә «зурлыйлар». Әмма, күренеш буларак, үзенең җаһил табигате белән әлеге каза отыры азыныргa, колачын бик киң итеп тә җәяргә мөмкин. Чыннан да, соңгы елларда Көнбатыш илләрендә (АКШ, Англия һ.б.) икейөзлелек инде хәтта дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә дә күтәрелде. Якын Көнчыгыш һәм Азия илләре дә алардан калышмый. Россия исә бу исемлектә аерым урын алып тора. «Валдай» дигән халыкара бәхәс клубының узган атнада (24-27 октябрь көннәрендә) Мәскәүдә үткән XIX утырышының пленар сессиясе барышында бу инде бигрәк тә ачык чагылыш тапты.

Искәртеп үтик, «Валдай» клубы глобаль процессларда Россиянең урынын тәгаенләү ниятендә экспертлар белән киңәш-табыш итү мәйданчыгы буларак, 2004 елда оештырыла. Быелгы утырышның темасы «Гегемониядән соңгы дөнья: гаделлек вә иминлек һәркем өчен» дип атала. Россия тирәсендәге катлаулы хәлләргә бәйле рәвештә, экспертлар бу юлы анда күбрәк Якын Көнчыгыш, Азия, Латин Америкасы, Африка һәм БДБ илләреннән (җәмгысы – 41 илдән 111 эксперт вә түрә) катнашкан. Ә алар игътибарына быел «Мир без сверхдержав» дигән доклад тәкъдим ителгән. Аның нигезенә «сверхдержава» төшенчәсенең үткәндә калуы турындагы гипотеза салынган. Оештыручылары исә анда Россия-Украина мөнәсәбәтләрендә килеп чыккан вакыйгаларның сәбәпләре вә нәтиҗәләре турындагы сорауга да җавап табарга тырышкан. Быелгы утырышның башка еллардагыдан үзгә максаты да шәйләнә: ул – Россия тирәсендә туган системалы кризис шартларында аны изоляциядә калмаган итеп күрсәтү. Сәяси аналитиклар фикеренчә, сессиядә быел алдынгы илләрдән җитди белгеч вә экспертлар катнашмау сәбәпле, ул таррак аудиториядә һәм креатив идеяләрсез диярлек үткән. Шуңа да карамастан, илнең гаммәви пропаганда чаралары ошбу гадәти вә гади вакыйганы Россиянең бернинди дә изоляциядә калмавын дәлилли торган факт итеп күрсәтергә тырышты.

Әлбәттә, форумның кульминациясе булып Россия Президенты В.Путин чыгыш ясаган һәм анда катнашучыларның сорауларына җавап та биргән пленар сессия торырга тиеш иде. Әмма чыгыш (бигрәк тә аның беренче өлеше), асылда, Көнбатышны сүгүгә кайтып калды. Менә алар: дөньяның энергетика һәм азык-төлек базарын тотрыксызландыру; гомумевропа газ үткәргечләрен юкка чыгару; аерым илләрнең һәм халыкларның суверенлыгын кире кагу, аларның үзенчәлек вә уникальлеген танымау һ.б. Нотыкта кемдер хәтта авторитар диктат куллануда да гаепләнде... Тәнкыйть уты Көнбатышны гына өтә. Президент әйтүенчә, Көнбатышның ошбу хәтәр дә, канлы вә пычрак та уенда үзәккә куйган төп максаты – дөнья өстеннән хакимлек итү. Шуңа ул барлык илләрне дә үзе урнаштырган кагыйдәләр кысасына куып кертмәкче икән. Бүген күп кенә өлкәләрдә глобаль колач алган системалы кризисны президент шуның нәтиҗәсе дип саный һәм монда ул, мөгаен, хаклыдыр да. Әмма бөтен гаепне Көнбатышка гына аударып калдыру да дөресләккә туры килмәс иде.

Форумда Путин Көнбатышның бары тик үз кыйммәтләре белән яшәве, аларны башка халыкларга да көчләп тагуы, ә инде «берполярлы» дөнья шәйләнгәч, аларның мәдәниятен, сәнгатен һәм мәгарифен бөтенләй кире кагуы һәм моның расачыл характер вә неоколониаль формалар да алуы турында ачынып сөйләде, мондый хәл хәтта идеологик каршы торуның «салкын сугыш» чорында да мөмкин булмавын искәртте. Әле шунда ук ул, Россиядә диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрдә үзара аңлашып яшәүнең хәтта уникаль культурасы урнашты дип тә белдерде. Әмма илдәге төп халыкларның милли мәгарифләре дәүләт тарафыннан җимерелүе, туган телләре мәктәпләрдән куылуы, аларның хәтта үз хокукларын парламентта яклау мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителүе турында ләм-мим. Илдә диннәрнең сәясәт коралы итеп кулланылуы, өстенлек нәсара диненә бирелүе хакында да президент бер сүз дә әйтмәде. Шуңа да карамастан, аның матбугат хезмәте, ошбу «фәлсәфи» чыгыш әле алга таба да кат-кат өйрәнелер, дип юрый. Булыр! Тик, сәхифәдә урын калмавы безне әлегә тукталып торырга мәҗбүр итә. Насыйп булса, мәсьәләнең фәлсәфи ягына инде киләсе язмабызда тукталырбыз.

Фоат УРАЗАЙ.

Белгечләргә ихтыяҗ зур

Казанда Бөтенроссия мөселман мәгариф оешмалары укытучылары форумында Саратов, Оренбург, Уфа һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең һөнәри уку йортлары директорлары, мөгаллимнәре катнашты. Пленар утырышта ясалган чыгышларда Татарстан һәм Россия өммәте ихтыяҗы өчен көндәшлеккә сәләтле татар телле имамнар әзерләү темасы күтәрелде. Чыгыш ясаучыларның һәрберсе моның кирәклеген ассызыклады һәм проблеманы чишү юлларын тәкъдим итте.

Бу мәсьәләгә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин аерым игътибар бирде. Ул чыгышында билгеләп үткәнчә, Татарстанның ислам уку йортлары республика мәчетләре өчен генә түгел, ә бөтен татар дөньясы өчен кадрлар әзерли. Бу белгечләргә Россиянең татарлар тупланып яшәгән төрле төбәкләрендә һәм БДБ илләрендә ихтыяҗ зур. Димәк, имамнар татар телен белмәсә, көндәшлеккә сәләтен югалтачак. Шул ук вакытта Камил хәзрәт искәрткәнчә, Татарстанда мәдрәсә һәм ислам югары уку йортлары, беренче чиратта, республика өметен канәгатьләндерергә һәм уку процессын аның ихтыяҗларыннан чыгып оештырырга тиеш.

Форум кунаклары «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, белем бирү учреждениесенең 140 еллыгына багышланган, фәнни конференциядә катнашты. Конференция мәдрәсәнең быел зур юбилей уңаеннан төзелгән яңа корпусында үтте. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә шушындый киң составтагы фәнни җыен беренче тапкыр уза! – диде фәнни җыенда К.Сәмигуллин. – Бу, һичшиксез, зур шатлык һәм мәдрәсәнең алга зур адым атлавын исбатлый торган ачык күрсәткеч. Аның стеналары буш торсын өчен төзелмәде: биредә тормыш кайнарга, мәгърифәт нуры сибелергә, фән алга атларга тиеш. Кайчак шәкертләребез килеп, үзем өчен генә укыйм, диләр. Бу дөрес түгел. Чөнки безгә «Имам буласым килә!» – дигән егетләр кирәк. Шул өлкәгә күбрәк басым ясау зарур».

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директоры урынбасары Зөлфәт Габдуллин югары квалификацияле белгечләр җитмәвен әйтте. «Дини уку системасының 30 еллык тарихы булса да, яңарыш кына безгә үсеш бирде. Яшьләр дингә бик күп килә, фикер йөртүләре заман таләбенә җавап бирә. Алар яшьләр телендә мәгълүматны аңлата белергә тиеш. Бу безнең югары квалификацияле белгечләргә мохтаҗлыгыбызны күрсәтә», – диде ул.

Курчаклар әнкәсенең юбилее

«Әкият» Татар дәүләт курчак театрында Татарстанның халык артисты Рәмзия Фәйзуллинаны юбилее белән тәбрик иттеләр. Татарстан мәдәният министры урынбасары Ю.Әдһәмова аңа «Мәдәниятәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе тапшырды.

«Әкият» курчак театрында беренче булып Фоат Таһиров Татарстанның халык артисты исеменә лаек була. Рәмзиябез – бу дәрәҗәле исемне алган икенче артист. Р.Фәйзуллина 43 ел буе сәхнәдә гел героиняларны башкарды. Аннан соң театрыбызның татар труппасына байтак артистлар килсә дә, Рәмзиядәй баш рольләрне башкарырдай, аны алмаштырырдайлары әлегә юк», – диде «Әкият»нең озак еллар эшләгән элекке режиссеры Илдус Насыйх улы Зиннуров. Иҗат кичәсендә Ф.Яруллин әсәре буенча куелган «Йолдыз тапкан кыз», И.Зәйниев пьесасы нигезендә сәхнәләштерелгән «Әлфия», шагыйрь Зөлфәтнең «Таңга – Чулпан, Айга – Зөһрә», Т.Миңнуллинның «Әлмәндәр» спектакльләре, «Камыр-батыр» әкиятеннән өзекләр башкарылды. Һәркайсында – Р.Фәйзуллина баш рольдә. Иҗатта шундый зур үрләрне яуларга аңа матур җырлау сәләте ярдәм итә. Илһам, Зөһрәләр кебек моңлы Сарман кызын иҗат кичәсендә якташлары, театр әһелләре һәм җырчылар Зөһрә Шәрифуллина, Илгиз Мөхетдинов, композитор Эльмир Низамов җыр, музыка аша тәбрикләде. Чыгыш ясаучыларның барысы да Р.Фәйзуллинаның кешелеклелеген билгеләп үтте. Чыннан да, бүген ул труппага яңа килеп кушылган яшь артистларга курчак уйнау сәнгатенең серләренә төшенергә ярдәм итә. Шундый сәхнә «балаларының» берсе Ләйсән Миннәхмәтова рәхмәт йөзеннән юбиляр актрисаның кичәсе өчен сценарий язган, үзе үк аны сәхнәгә куйган.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Укытучыларны зурладылар

Казанда Бөтендөнья татар конгрессы үткәргән «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» интернет-бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Анда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» генераль директоры Илшат Әминов катнашты.

Д.Шакиров җиңүчеләрне Татарстан Премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев исеменнән котлады.

И.Һадиуллин мөгаллимнәр балаларга тормышта үз юлын табарга, сәләтләрен ачарга, чын шәхес тәрбияләргә ярдәм итүен ассызыклап, бәйгедә җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

Тантанада шулай ук Резеда Төхфәтуллина, Миңгол Галиев, Резидә Шәрәфиева һ.б. чыгыш ясады.

1 нче биттә – Казанның Авиатөзелеш районындагы 5 нче гимназиядә узган «Аулак өй – баттл» бәйгесеннән бер күренеш. В. Васильев фотосы. «Татар-информ».

Кыргызстанга гыйбрәтле сәфәр

Әтнә Татар дәүләт драма театры артистлары Кыргызстаннан кайтты. Театр анда беренче тапкыр 2018 елда мәшһүр язучы Чыңгыз Айтматовның юбилее уңаеннан аның әсәре буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклен алып барган була. Шуннан соң Кыргызстаннан вәкилләр үзләре әтнәләргә кунак төшә. Танышып, аралаша торгач, Кыргызстандагы милләттәшләребез Әтнә театры артистларының ихласлыгы, гадилеген ошата, күрәсең. Әтнә театры – авыл җирлегендә урнашкан бердәнбер профессиональ труппа. Аның иҗатында авылча самимилек тә, һөнәрмәндлек тә бергә кушылган. «Сәхнәдәге фольклор коллективларының ялтыравыклы костюмнарыннан тәмам туйган идек. Сез безгә чын, тормышчан костюмнарны күрсәттегез», – дигән Кыргызстанда гомер кичереп, татар милли киемнәре турында әби-бабалары сөйләгәннәрдән генә белгән милләттәшләребез. Шуңа күрә, мөгаен, Президентыбыз Р.Миңнеханов 2021 елда Кыргызстанга эшлекле сәфәргә баргач, андагы татар җәмгыяте рәисе Гөлсинә Үлмәскулова илбашыннан Әтнә театрын җибәрүен сорагандыр. Шула итеп Әтнә коллективының чираттагы бу сәфәре президентыбыз ярдәме белән оештырыла. Артистларыбыз Бишкәк, Җәләл-Абад, Каракол, Ош шәһәрләрендә була. Тамашаларын ике меңгә якын тамашачы карый. Театральләштерелгән концерт программасының сценариен шагыйрә, маркетинг буенча директор урынбасары Гөлүсә Баттал яза. «Озын җөмләләрне кыскартырга, кайбер сирәк кулланыла торган әдәби сүзләрне синонимнары

● «Гүзәлем Әсәл» спектакленнән.

белән алыштырырга туры килде, чөнки, ни кызганыч, тел проблемасы Кыргызстандагы милләттәшләребез тормышында да кискен тора, безне аңламаулары ихтимал иде», – диде Г.Баттал сәфәрдән соң «Татмедиа» агентлыгында узган матбугат очрашуында. Тамашачы аеруча баянга кушылып җырланган җырларны яраткан. Әтнәләләр Татарстанга кайтырга өлгермәгәннәр, Кыргызстандагы милләттәшләребез концертта яңгыраган җырларның язмаларын юллауны сорый башлаган. Театрның артисты консерватория тәмамлаган Реваль Хисмәтуллин башкаруында кайбер җырларны Иссык күл янында яшәүче милләттәшләребезгә җибәргәннәр. Әйтүләренә караганда, Кыргызстанда затлы нәселләрнең төрле елларда кысу-кысрыклаулардан качып күченергә мәҗбүр булган дәвамчылары яши. Алар һәр эштә беренче, шуңа күрә Кыргызстанда татарларга хөрмәт тә зур. Татарстаннан килгән театр коллективын шулай ук өрмәгән җиргә утыртмаганнар.

Директоры Ленур Зәйнуллин Әтнә театрының якын киләчәккә планнары белән дә таныштырды. Театрның нигезендә торган Гомәр Мәрдәновның туган көне уңаеннан 18, 19 ноябрьдә А.Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Кар астында кайнар чишмә» спектаклен тәкъдим итәчәкләр. ГИТИСта укучы Гөлназ Минкина балалар өчен Яңа ел тамашасын сәхнәләштерә. Былтыр Г.Мәрдәнов истәлегенә мәктәп театр коллективларының театр фестивален башлап җибәргәннәр иде. Быел шунда күзгә чалынып калган иң талантлы балалар белән спектакль сәхнәләштермәкчеләр. Г.Минкина куелышындагы әлеге тамашаны 20 мартта күрсәтү каралган. Мартта Әтнә театры шулай ук Мәскәүгә гастрольгә барырга җыена. Иҗат фасылын исә драматург һәм режиссер Илгиз Зәйниев үзе язган, үзе куйган спектакль белән тәмамламакчылар.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Җыр һәм бию ансамбле бинасы аяныч хәлдә

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

2022 ел. «2019 елда Дәүләт җыр һәм бию ансамбле бинасына һәм ишегалды территориясендә ремонт-реставрация эшләре үткәрү өчен проект-смета документациясе әзерләнгән иде. Хәзерге вакытта түбә калае череп, ремонтлап булмас хәлгә килде. Түбәнең мондый хәлдә булуы фасадка куркыныч тудыра, һәм кирпечләрнең тротуарга ишелеп төшүе мөмкин».

«Дәүләт җыр һәм бию ансамбле бинасының түбәсе начар хәлдә. Түбә черегән, һәм су үтеп, кирпеч диварларга сеңә. Температура үзгәргәндә кирпечләр дивардан кубып, җәяүлеләр тортуарына һәм юлга ишелеп төшә. Авариядән саклану һәм җәяүлеләргә куркыныч тудырмау өчен, бинаның түбәсен ябудан башлап, этаплап ремонт мәсьәләсен карасагыз иде».

Бүген түбә ябарга күпмедер миллион сум акча табылса да, бу – проблеманың вакытлыча хәл ителеше генә булачак. Әгәр безгә ансамбльнең үсеше кирәк икән, иртәме-соңмы, яңа бина турында уйларга туры киләчәк. Чөнки бинага ремонт ясалса да, алга таба аның ансамбль ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмавы күренә. Бу – җитлеккән ир-атка малай бишмәте кидертеп куйган кебек. Сыймый ул анда.

Безгә җырчылар, биючеләр һәм оркестрның уртак репетициясен күрергә туры килде. Оркестр, җырчылар һәм биючеләр бөтенесе кергәч, репетиция алып баручы сәнгать җитәкчесе А.Хәмитовка бөтенләй урын калмады. Ул тәрәзә төбенә басып, эшен дәвам итте.

Мәгълүмат өчен: оркестрда 14 музыкант, 28 җырчы һәм

16 пар биюче эшли. Димәк, репетицияләрдә 74 кеше катнаша. Хормейстер, хореограф, сәнгать җитәкчесе белән 77 кеше була. Зал – 135 кв.м. Гап-гади арифметика 1 кешегә 1,75 кв.м туры килүен күрсәтә. Ул 77 кешенең 32 се биюче икәнен дә хәтердән чыгармыйк.

Кызык: 85 яшьлек ансамбльнең беркайчан да үз сәхнәсе булмаган. Ансамбльнең күп вакыты юлда уза. Алар дәүләт планын үти, кая чакырса да – баралар... Түбәләреннән су үтеп, дивар кирпече тротуарга ишелә башламаса, алга таба да шулай яшәрләр иде. Хәер, су үтсә дә яшиләр инде.

Хәзер бер кызык тенденция барлыкка килде: нинди дә булса оешма үзенә бина яки ремонт кирәклеге турында авыз ача икән, әһә, бу – Камал театры бинасына нәфесен суза, дип уйлыйлар. Әмма ансамбль очрагында һич тә алай түгел. Камал театры бинасы ансамбльгә берничек тә туры килми. Чөнки ансамбль ул – беренче чиратта сәхнә түгел, ә репетицияләр залы.

А.Хәмитов: «Химиклар мәдәният сарае да, Камал театры бинасы да безнең өчен түгел. Мин дәүләт ансамбленең киләчәктәге урынын иске аэропорт бинасында күрәм. Бу – минем хыял. Анда репетицияләр заллары да, зур концерт залы да ясап булыр иде. Аның урыны безгә килешеп тора.

Ансамбль өчен репетиция базасы сәхнәгә караганда да мөһимрәк. Вокал класслары, душ бүлмәләре, гримеркалар кирәк. Аларны кешегә күрсәтергә оят. Биегәннән соң тирне тизрәк юып төшерү – элементар гигиена. Ләкин андый мөмкинлек юк. Биючеләрнең күбесе, душ бүлмәләренә чират көтеп тормыйча, машинасына утырып, өенә кайтып китә.

Безнең бит әле балалар да бар. 50 бала йөри торган студия эшли. Биредә шөгыльләнүче балаларга шартлар тәкъдим итә алмавыбыз өчен уңайсыз. Әти-әни баланы ансамбль брендына кызыгып алып килә. Ә без нинди шартларда? Студиягә йөрүчеләр бинаның бердәнбер залында ансамбль артистлары кайтып киткәч шөгыльләнә».

Белешмә: «Юлдаш» студиясенә йөрүчеләр биредә биюне генә түгел, музыкаль грамотаны да, ансамбль тарихын да өйрәнә. Студиянең максаты – алар арасыннан ансамбль йолдызы булырлык биючеләрне табу. Талантлыларга хореография училищесына барырга тәкъдим ителә.

Ю.Жуков: «Башкортстанда дәүләт ансамбле каршындагы студиягә 300 бала йөри. Безнең – 50. Без дә бит күпләп укыта, йөзләгән баланы милли ансамбль аша уздыра алыр идек! Моны бүген эшли алмасак, 15 елдан бу беркемгә дә кирәкмәячәк...»

Бинаның кирәклеге – республиканың «визит карточкасы», бренды булган ансамбльнең бүгенгесе һәм үсеше генә дә түгел, ул милләт язмышы, телебез язмышы да. Милли ансамбльдә биегән балага барыбер милли хис сеңә. Аның күзәнәкләрендә яткан миллилеге уяна. «Милли код», «мәдәни код» дигән төшенчәләр шушы түгелмени?

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

intertat.tatar

Зыялы артист иде ул...



Татарстанның театр сәнгате зур югалту кичерде: 30 октябрь көнне Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, милли сәхнәбезнең якты йолдызларыннан берсе Николай Иван улы Дунаев (Наил Дунаев) вафат булды.

Николай Дунаев 1937 елның 3 маенда Татарстанның Зәй районы Әхмәт авылында туа. 1961 елда Мәскәүдә Щепкин исемендәге Югары театр училищесын (татар студиясе) тәмамлый һәм Татар академия театрында эшли башлый. Төрле планда төп рольләр башкаручы киң диапазонлы танылган артист булып таныла. Күп кенә сәхнә образларыннан аның иҗади йөзенә хас булган ягымлы зыялылык бөркелә, шул ук вакытта алар көчле кичерешләр һәм хисләргә тулы эчке киеренкелек, ышандыру көче белән сугарылган. Актерлык хезмәте белән бергә театр өчен пьесалар тәрҗемә итә. Казан мәдәният һәм сәнгать университетында актерлык осталыгы буенча укыта.

Н.Дунаев – Татарстанның М.Җәлил һәм Г.Тукай исемендәге премияләр лауреаты иде.

● Татарстан юлларында камералар тагын артачак. Юл кагыйдәләрен бозу очракларын терки торган әлеге җайланмалар республикада илдә беренчеләрдән булып 2008 елда урнаштырылган иде. Ул чакта барлыгы 66 комплекс куелган булса, хәзер инде аларның саны 897 гә җиткән. «Сыйфатлы имин юллар» федераль программасын гамәлгә кертү кысаларында ел азагына кадәр тагын 88 камера урнаштыру планлаштырыла.

● Быелның беренче 7 аенда гына да Татарстанда юл кагыйдәләрен бозучыларга карата 4 миллион эш ачылган, шуның 3,5 миллионы – фотовидеотеркәү җайланмалары ярдәмендә. Быелның 9 аенда Татарстанда 50 меңнән артык машина йөртүче иминлек каешын куллану кагыйдәләрен бозган өчен административ җавапка тартылган – аларга меңәр сум штраф салынган.

Төбәк тарихчылары – ЕКАТЕРИНБУРГТА

Милләттәшләребезнең тарихын барлауга багышланган «Урал ягы татарлары: тарих һәм заман» VII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең чираттагы утырышы Екатеринбург шәһәрендә узды.

Тарихта канлы вакыйгалар, аеруча көчләп чукындырудан качу татар халкын дөнья буйлап тараткан. Әмма татарлар беркайда да югалмаган. Екатеринбургтагы төбәкне өйрәнүчеләр эш башлап җибәргән Агафуровлар йорты безгә шундый булдыклы милләттәшләребезнең берсен искә төшерде.

Галим А.Борһанов җитәкчелегендә татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрне 1887 елда төзелгән Агафуровлар йортында урнашкан Татарстанның даими вәкиллегендә Татарстанның Свердловск өлкәсендәге даими вәкиле урынбасары, «Саф чишмә» газетасы редакторы Фәвия Сафиуллина һәм Татарстанның Урал төбәгендәге даими вәкиллеге консультанты Рифат Йосыпов каршы алды.

Агачны кисеп һәм уеп эшләнгән бизәкләре һәм матурлыгы белән теләсә кемне җәлеп итәрлек һәм тирә-юньгә ямь биргән Агафуровлар төзегән йортларның тышкы рәвешенең матурлыгына сокланып торганнан соң, аларның тарихы белән дә кызыксындык. Нәселнең бу якларда тамыр җибәрүе Лаеш районының Кече Елга авылыннан бай күршесенең улы өчен шактый зур акча бәрабәренә солдат хезмәтен үтәргә ризалашкан Хисаметдин Агафуровтан башланган. Әлбәттә, ир-егет чит-ят җирләргә яхшы тормыштан чыгып китмәгән, Гафур абзыйның бер генә улы, биш кызы үсү сәбәпле, гаиләне туендырырлык имана җире булмаган. Солдатның авылда хатыны һәм кечкенә баласы кала, алар да бер елдан Екатеринбургка килеп, фатир арендалап яши башлый. Хисаметдин төрле курсларда белем ала һәм әкренләп сабын, шырпы, чәй, җиләк-җимеш, хушбуй, шулай ук алтын һәм көмеш бизәнү әйберләре белән сәүдә итә башлый. Ярдәмчеләре исә – кечкенә уллары. Хисаметдиннең уллары Камалетдин, Зәйнетдин, Кашафетдин әтиләренең вафатыннан соң да аның эшен уңышлы дәвам итеп, XIX гасырда сәүдә йортлары челтәрен булдыра. Агафуровлар 1884 елда «Борадәр Агафуровлар» ширкәтен төзи. Алар ширкәтенең Төмәндә, Эрбет ярминкәсендә, Пермьдә, Варшавада һәм Мәскәүдә күпләп һәм ваклап сату бүлекчәләре эшләгән. Агафуровларның юмартлыгы хакында аларның Екатеринбургта мәчет һәм мәктәп төзетүләре, аларны матди тәэмин итеп торулары да сөйли. Бертуганнарның шулай ук Нижний шәһәрендә мәктәп һәм имам өчен йорт салдыруда булышуы, Санкт-Петербургта җәмигъ мәчете төзелешенә акчалата ярдәм итүе дә теркәлеп калган. Агафуровлар өлкән яшьтәге кешеләргә, авыруларга, ятимнәргә ярдәм кулы сузган.

Алар спорт белән шөгыльләнгән, велосипедлар өчен беренче юлларны да салган, Агафуровлар акчасына ипподром төзелгән, шулай ук Мөселман җәмгыятен дә оештырганнар. Бертуганнар яхшы белем алган, итагатьле, гадел булган. Екатеринбургта аларның дәрәҗәсе әле дә бик зур.

Екатеринбургта сәүдәгәр Агафуровларның бер-берсеннән ерак түгел ике йорты сакланып калган. Аларны шәһәрнең агач энҗесе дип йөртәләр. Биналар, агач сәнгатенең искиткеч үрнәге буларак, төбәк әһәмиятендәге архитектура һәйкәле дип танылган, әмма әлегә алар шактый мөшкел хәлдә.

Фәвия Сафиуллина искәрткәнчә, бинага 50 еллар дәвамында зурлап төзекләндерү эшләре алып барылганы юк. 2018 елда Татарстан Президенты Р.Миңнеханов, Екатеринбургка килгәннән соң, йортның шундый хәлдә икәнлеген күргән һәм өлкә губернаторына тәкъдим белән чыккан. Ул исә бу йортны Татарстанның даими вәкиллегенә 20 елга бушка (вәкиллек 50 елга сораган була) арендага тапшырырга риза була. Аның хисабына Татарстан акча бүлеп, шушы йортны төзекләндерергә тиеш, дип килешенә. Шулай итеп Екатеринбургның бизәге булган йортны ремонтлауны җиңел генә Татарстан җилкәсенә салып куялар.

Бинаны 2019 елдан төзекләндерә башлаганнар. Әлеге бинаның нигезе генә ныгытылган. Һаман документлар әзерләү бара. «Берике елдан бу бина элекке матур рәвешенә кайтыр, дип ышанабыз», – ди Ф.Сафиуллина.

Йортта шулай ук татар халкының милли мәдәнияте белән дә танышырга мөмкин. Бу килгән кунакларга милләттәшләребезнең милли киемнәре, гореф-гадәтләрен күзалларга мөмкинлек тудыру ниятеннән эшләнгән. Экспонатларны зур горурлык белән башка халыкларга тәкъдим итәләр. Бинаны һәм ядкярләрне губернатор, аның ярдәмчеләре дә килеп күргән. Калфак һәм түбәтәйләрне сорап та торгалауларын, ә инде чигүле читекләргә бик күпләрнең күзе кызуын әйтәләр. Витриналарга революциягә кадәр нәшер ителгән Коръән китаплары да куелган. Йортның бик матур верандасы да бар.

Бу бинада шулай ук якшәмбе мәктәбе дә эшли. Ул 1990 елларда ачылган. Беренче укытучысын да хәтерлиләр әле. Таңчулпан Жданова туган телен бик әйбәт белмәсә дә, күңелендә татарлыгы көчле була, милли киемнәр киеп, якшәмбе мәктәбенә килгән балалар белән татар калфаклары тегеп, бишек җырларын җырлап, дәрес алып бара. Соңрак мәктәпкә белемле укытучылар килеп, телебезне өйрәтә башлый. Биредә шулай ук атнаның һәр чәршәмбесендә онлайн дәресләр дә үтә. Аларга 25-30 кеше килә. Якшәмбе мәктәбенә шимбә яшьрәкләр, икенче көнне өлкәнрәкләр йөри. Рус мохитендә үскән ханымнар олыгая башлагач кына, үз тамырларына тарихыбызга кайту ягына борыла. Якшәмбе мәктәбенә рус малайлары да йөрү кызыклы. Алар, татар дусларыбыз бар, дип бераздан вата-җимерә булса да татар телендә сөйләшә башлый. Әлбәттә, мәктәпкә йөрүчеләр рәхәтләнеп татарча аралаша алмый, әмма аларга татарлыклары кайта.

Аннары төбәк тарихын өйрәнүчеләр Агафуровларның Татарстан вәкиллеге урнашкан бинадан ерак түгел икенче йортны да карады. Анда «Агафуровлар йорты» музей клубы урнашкан. Конференция кунакларын биредә экскурсия алып баручы Лариса Коновалова каршы алды һәм Хисаметдин һәм аның улларының тормышы, эшчәнлеге белән таныштырды.

Совет чорында бина, зур коммуналь фатир кебек кулланылган. Акрынлап ул яшәү өчен тулысынча яраксыз хәлгә килә һәм бары тик Бөтенроссия тарих һәйкәлләрен саклау җәмгыяте активистлары – җәмәгатьчелек ярдәме белән беркадәр торгызыла. Әмма икенче йортны да зурдан кубып төзекләндерү сорала.

Агафуровлар революцияне кабул итми һәм Ерак Көнчыгыш аша гаиләләре белән Кытайга һәм Японияга юл ала. Биредә калган туган-тумача, таныш-белешләренең бер өлеше репрессиягә эләгә, яңа власть тарафыннан атып үтерелә. Агафуровларның Россиядә булган барча мал-мөлкәте, кибет һәм йортлары советлар тарафыннан тартып алына.

Төбәкне өйрәнүчеләр шулай ук шәһәрнең Дуслык бакчасында куелган М.Җәлил һәйкәленә дә чәчәк салды. Бюстны кую җиңел булмаган, Екатеринбургта яшәүче милләттәшләребезгә шәһәрдә Җәлилгә һәйкәл булдыру турында берничә дистә ел хыялланып кына йөрергә туры килгән. Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе, Татарстан Премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразыев Екатеринбургка килгәч, хакимият вәкилләре белән очрашкач кына мәсьәлә уңай хәл ителгән. Әмма бюстны куяр өчен урын, татар җәмәгатьчелеге теләгәнчә, шәһәр уртасына түгел, Орджоникидзе районынан бүлеп бирелгән. Даими вәкил Хәйдәр Гыйльфанов, ТР Президенты янына килеп сөйләшкәннән соң, Җәлил бюстын ясау өчен акча да табылган. Постамент исә җирле хакимият акчасына торгызылган. Бюсят ачуга В.Шәйхразыев килгән. Һәйкәл янында Татарстан җитәкчеләре дә, Россия Герое Дамир Йосыпов та булган. Бюст хәзер Екатеринбургта татарларның җыела торган бер урынына әверелгән. Милләттәшләребез бирегә Җиңү бәйрәмендә дә, патриот-шагыйрьнең туган көнендә дә, 25 августта да килә, Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен искә алалар. Бюст янында өлкәннәр дә, якшәмбе мәктәбендә укучылар һәм татар авыллары мәктәпләреннән дә балалар еш була.

Ф.Сафиуллина Екатеринбургта 1993 елда беренче татарча телевизион тапшырулар алып бара башлый, 2001 елдан ул өлкә күләмендәге телевидениедә чыга. Әмма 2011 елда финанс кыенлыклары сәбәпле тапшырулар туктый. Хәзер өлкәдә «Саф чишмә» газетасы гына нәшер ителә. Свердлов өлкәсе татар конгрессы, Татарстанның Урал төбәге буенча Даими вәкиллеге һәм өлкә Халык иҗаты сарае ярдәмендә күп кенә конкурс, фестивальләр үтә.

Ф.Сафиуллина шулай ук өлкәдә 11 иҗтимагый оешма эшчәнлек алып баруы, 19 гомуми урта белем бирү мәктәбендә татар теле дәресләре кертелүе турында да белдерде. «Тукай һәм Җәлил укулары», Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре, Юныс Әхмәтҗанов истәлегенә татар ашлары фестивальләре дә гөрләп уза. Әмма өлкәдә татар теле һәм сәнгате белгечләренә кытлык булуы борчу тудыра. «Туган телебезне өйрәтү өчен дә, талантлы яшьләрне җырбию сәнгатендә үстерү өчен дә вокал, хореография укытучылары җитми», – ди Ф.Сафиуллина.

Чираттагы тукталыш – Каменск-Уральский шәһәре. Биредә безне җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Илдар Сафин каршы алды. Имам чыгышы белән Татарстанның Кама Тамагы районыннан, 7ел элек бирегә килеп төпләнгән. 30 меңләп татар яшәгән шәһәр өчен 1993 елда төзелгән мәчет кысанланган. Илдар хәзрәт Аллаһ йортының бинасын киңәйтү эшен алып бара. Октябрь аеннан мәчеттә татар теле дә өйрәтелә, гарәп графикасы һәм теле, ислам дине нигезләре дәресләре алып барыла. Усман авылыннан Талип ага Мәгафуров аларны Казанда нәшер ителгән дәреслекләр кулланып укыта. Мәҗлестә 11 яшьлек Тимур Мирхәйдәровнең Коръән сүрәләрен яңгыратуы барыбызның да күңеленә хуш килде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары

Сагындырып искә төшә...

(Танылган журналист, нәшир Шәех Зәбировның тууына 90 ел)

● Газетада басылачак һәр язма башта аның күзе, күңеле, җаны һәм үткен каләме аша уза.

Татар журналистикасында зур шәхес булган Шәех абый Зәбировка, исән булса, бу көздә 90 яшь тулыр иде. Гадәттәгечә, аны гомер буе зурлап яшәгән Фәния апа Хуҗахмәт аның белән эшләгән, аралашкан, аны хөрмәт иткән барча каләм әһелен, туган-тумачасын затлы бер залга мул табын артына җыяр, Коръән укытыр, вәгазь тыңлатыр иде. Тик яраткан Шәех абыебыз, остазыбыз, гел кирәкле булып аяк өсте йөгереп йөргән җиреннән, бөтен халык шигърият мәйданында Тукайны яд иткәндә, кинәт кенә арабыздан мәңгелеккә китеп барды шул. Алдымда яткан «Безнең Шәех» дип аталган хатирәләр китабын Фәния апабыз аның вафатыннан соң өч ел үтүгә бастырып, барчабызга бүләк иткән иде. Шәех абый турында замандашларының, хезмәттәшләренең, якыннарының күпме җылы хатирәсе тупланган анда! Җыентыкта урын алмаса да, бу олпат зат турында минем дә үз хатирәләрем күңел түремдә саклана.

Университетны тәмамлагач та, ул чакта милләт юлында көрәшүчеләрнең рупорына әйләнгән яшь басма – «Шәһри Казан» газетасына эшкә килдем. Шунда эшкә өйрәнеп, матбугат эшенә гашыйк булып кына калмадым, гомерлек мәхәббәтемне – Искәндәрне дә очраттым. Тик кулны кулга тотышып, чәчләр чәчкә бәйләнгәнче, шактый сынаулар аша да үтәргә туры килде. Йөрәгем сайлаган кешене, нахак бәла ягып, хөкем иттеләр. Ул көннәрдә бергә эшләгән, аралашкан кешеләрнең күпчелеге аннан йөз чөерде, ачыктан-ачык та, читләтеп тә аның белән аралашуның юньлегә илтмәячәге турында сиздереп торалар иде. Тик бу авыр чакта да хәлебезне аңлаучы, ярдәм итүче, догада торучы олы йөрәкле кешеләр очрап торды. Шуларның иң хөрмәтлеләре – Шәех абый белән Фәния апа булды, дисәм, ялгышмамдыр. Шәех абый ул чакта «Мәдәни җомга» редакциясендә җаваплы сәркатиб булып эшли, Фәния апа шунда бер бүлмәдә үзенең бөтен татар дөньясына тарала торган "Татар-мөселман календаре"н чыгарып ята иде. Мин бу вакытта инде «Мәдәни җомга»га эшкә килдем. Шәех абый зур гәүдәсе, карап торышка кырыслыгы белән баштарак коры булып тоелса да, тиз арада аның киң күңелле, яшьләргә, аеруча талантлы кешеләргә хәерхаһлы бер сабый күңелле кеше икәнен төшендек. Ул кайчан карасаң, үзенең бүлмәсендә тау кебек кульязмалар, фотолар өелгән эш өстәле артында утырыр, сантиметрлы линейкасын юантык бармаклары арасында уйнаткалап, язмаларны үлчәр, газета битендәге урыннарын исәпләр, гомумән, басманың тышкы кыяфәтен иҗат итәр, һәр язмага шул тукымада үз урынын табар иде. Кайсыдыр язмаң озаграк чыкмый ятса, Шәех абый янына керәсең, эчеңнән генә «башы беткәндер инде, бу кадәр кәгазь арасыннан каян таба алсын…» дип уйлыйсың. Ә ул җәһәт кенә теге тауның үзе генә белгән ноктасыннан кирәкле язманы тартып та чыгара. Гомумән, Шәех абыйда бер генә фото да, бер язма да югалмый иде. Ул чакта бит әле барлык архив хәзерге кебек компьютер хәтерендә сакланмый, ә Шәех абыйның хәтерендә туплана иде. Менә шушы эш аты булган олы йөрәкле Шәех абый Искәндәр турында, башкаларга ияреп, бер яман сүз дә әйтмәде, аның белән аралашмаска өндәп нотация укымады. Киресенчә, якын кешемнең хәлен белешергә рәшәткә артына барырга җыенуымны белүгә, ул кулыма саллы бер китап тоттырды: «Менә, Фәния апаңнан бу, Искәндәргә тапшыр», – диде. Бу Коръән китабы иде… Билгеле, Коръәнне илтеп тапшырдым. Якын кешем иреккә чыкканчы, Шәех абый белән Фәния апа аның өчен борчылып, хәлләрен белешеп, ут йотып торды. Һәр авырлыктан соң җиңеллек булыр, диелгән Коръәндә дә. Бу ике гүзәл кеше соңрак әти-әниебез янәшәсендә түребездә туй мәҗлесебездә дә утырды. Сынауларны үтеп, сынмыйча, өр-яңадан үзен исбатларга һәм татар матбугатында Искәндәр Сиражи булып танылырга Шәех абый, Фәния апа кебек шәхесләрнең ышанычы рухи таяныч булды.

Шәех абый үзе дә олы тормыш юлы үткән, ачысын-төчесен җитәрлек татыган кеше, шуңа күрә дә ул башкаларның хәленә керә, аңлый, кызгана белә, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша иде. 1932 елда Кыргызстанның Ош шәһәрендә аваз салса да, Тимершәех атлы малайга тауларның кызу һавасы килешми, гаилә кире туган төякә – Лениногорск районының Сарабиккол авылына әйләнеп кайта. Харис абзый көттереп туган улына исемен үзгәртеп, колагына Миншәех дип кычкырта. Шәех сүзенең дәрәҗәне аңлатуын, ислам диненә хезмәт иткән олы шәхесләргә әйтелүен һәм үз улының да Аллаһ дине юлында иҗтиһад кыласын башына да китермәгәндер ул. Тик сугыш башлану Шәехнең балачагын урлый. Сугышның башыннан ахырына кадәр үгез җигеп колхозда эшли. Җитмәсә, 1943 елда әтиләре сукырая. Бөтен байлыкны кырып-себереп, Казанга бер тәпән бал илтәләр, шул хакка әтиләренең күзен ачтыралар. Тик сугыш бетеп тә авылга җиңеллек килми, тамаклары ипигә туймый, халыкның тормышы яхшырмый… Сарабикколның 13 үсмер малае шул караңгылыктан чыгу юлын эзләп, «Ленин юлыннан» дигән яшерен оешма оештыра. Илнең алга бармавын алар Ленин юлыннан тайпылуда күрә. Шәехкә резинадан шрифтлар кисеп, листовкалар әзерләү эше йөкләнә. Төнге буе кеше күзеннән качырып, хәреф кисә малай. Тик бу эш озак бара, кулдан гына язып торырга уйлыйлар. Листовкаларны язып, авыл буйлап тараталар, халыкны дөрес юлны кайтарырга өндиләр… Әлбәттә, үсмерләрнең эзенә тиз төшәләр. Гаугасы Мәскәүгә хәтле ишетелсә дә, мәктәптә бер укытучыны да калдырмыйча кусалар да, төп оештыручы «диссидентлар» бу бәлаләрдән нинди хикмәт беләндер исән-сау чыга. Халыкның контр дип кырын караулары, җиденчене бетергәч, документ бирми җәфалауларыннан гарык булып, Шәех бер ел элегрәк киткән этисе артыннан яңадан Ташкент якларына чыгып китә. Юлга акча юнәтер өчен, соңгы кәҗәне суеп сатала. Озатканда күрше карчыгы, рәхмәт төшкере, бер савыт бал бирә. Ташкентка 18 тәүлек бара Шәех. Карыны ачкан саен, савытка аз гына су салып чайкатып эчә. Барып җиткәндә ачлыктан хәлсезләнеп шәүләсе генә калган була аның... Алда – бизгәк белән чирләп, яшәү белән үлем арасында бәргәләнү, кабат авылга кайту, үгез җигеп симәнә ташулар… Шөгердә урта мәктәпне тәмамлап, комсомол секретаре булып, «Яшь сталинчы» газетасының актив хәбәрчесе булып танылып, 1953 елда Шәех Казан университетына укырга керә. 1958 елдан ул «Татарстан яшьләре» газетасына эшкә килә, аның татар матбугатындагы саллы юлы шул көннән башлана.

1960 елда яңадан чыга башлаган «Яшь ленинчы» газетасының да беренче макетларын ул сыза. 1963-1965 елларда ул мөхәррир булып эшләгән чорда яшьләр газетасының тиражы 18 меңнән 68 меңгә җитә! Идеология кайчысы өстендә эленеп торган, ялгыш язган бер сүз өчен дә бюрога җыеп тикшерә торган еллар бу.

Аннары – «Социалистик Татарстан» газетасында егерме еллык җаваплы сәркатиб хезмәте. Идеология сөреме белән никадәр тынны бусалар да, кеше язмышы турында язарга, үзәккә кеше күңелен куярга җаен таба, шул юлда эзләнә Шәех абый. Яңына талантлы журналистларны туплый.

Аннары – милли яңарыш җилләре белән сугарылган «Шәһри Казан»ны оештыру, беренче макетларын сызу, җаваплы сәркатиб булып, яңа матбугатны аякка бастыру…

Без танышканда исә, Шәех абый чираттагы «баласы» – «Мәдәни җомга» газетасында җиң сызганып җаваплы сәркатиб эшен алып бара иде. Ул баһадир гәүдәле, зур башлы, нык кеше, нәрсәдәндер оялып, сабыйларча кызарып та чыга. Үз гомерендә катлаулы чирләрне дә җиңәргә туры килде аңа. Адәм баласының гомере бетмәсә, нинди чир дә җиңә алмый дисәләр дә, аңа яңадан тормышка кайтырга, тагын озак еллар җиң сызганып матбугатта эшләргә хәләл җефете Фәния апаның кайгыртуы, җан җылысы да сәбәп булгандыр. Гомумән, ирен шулкадәр кайгырткан, зурлаган, хөрмәтләгән башка хатын-кыз бармы икән? Яшьлек шаукымы белән корган беренче гаиләсендә чит милләттән, чит диннән булган хатыныннан җан җылысы күрми йөдәгән Шәех абыебызга ниндидер изгелекләре өчен гомеренең соңгы өлешенә Аллаһтан бирелгән бер бүләк булгандыр ул, дим. Фәния апа аны энә-җептән генә кыйммәтле киемнәргә киендерә, алдыннан тәмле ризыкны өзми. Туганнарын хөрмәтли, шәп машиналарда йөртә…

Шәех абыйның матбугат эшчәнлегендә татарча календарьлар чыгару саллы урын алып тора. Шул календарьлары өчен ул журналистларның Х.Ямашев исемендәге премиясенә дә лаек була. Гомеренең соңгы дистә елларында исә Шәех абый, матбугат эше белән беррәттән, үзе нигезләгән "Татар мөселман календаре"н да нәшер итте. Фәния апа белән алар бу эшне шулкадәр күңел биреп, җан куәтен салып алып бардылар ки, юкка гына бу басма 29 ел буе халкыбызның яраткан өстәл китабы булып тормыйдыр. Алар татар тарихына, динебезгә кагылышлы дистәләгән исемдәге китап, Коръән тәфсирләре дә әзерләп бастырды, халыкка ирештерде. Заманында өч хәрефле оешмаларның гомерлек күзәтүе астында яшәргә мәҗбүр булган парторг Шәех абыйга изге гамәлләренә күрә Аллаһка якынаеп, бәрәкәтле гомеренең соңгы елларында намазга басарга, Хаҗ кылу бәхетләренә ирешергә насыйп булды. Ул муллалар, дин әһелләре белән аралашты, хәзрәтләрнең вәгазьләрен, сорауларга җавапларын туплап китаплар чыгарды, шул китаплар күпме кешегә иманга килергә, кыйбласын табарга ярдәм итте. Шуңа күрә дә аны онытмыйбыз, халкыбызның сөекле улы, милли матбугатыбызның аксакалы буларак, тууына 90 ел тулган көннәрендә дога белән искә алабыз. Һәркайсыбызга үз артыбыздан Шәех ага кебек яхшы сүз, изге эшләр, мәгънәле китаплар, рухи байлык калдырырга насыйп итсен иде.

Эльмира СИРАҖИ.

ӘЛЕ ДӘ ГАРМУНЧЫЛАР БАР!

Рамил Курамшинга

Гармунчыларга кызыгып
Үстем бала чагымнан.
Көннәр буе чыкмый идек
Мунча алачыгыннан.

Гармунда уйнарга шунда,
Җыйналып малай-шалай,
Өйрәнәбез көннәр буе.
Остазыбыз – бер малай.
Тальянда уйнау серләрен
Ул гына белә иде.
Колагыңа аю баскан,
Дип миннән көлә иде.
Гармунчы була алмадым,
Колакка баскач аю.
Гармунда уйнауның да шул
Бардыр ул берәр җае.
Эх, уйный белсәң иде ул
Гармунның тәмен белеп,
Рәшит Мостафин шикелле,
Рамил Курамша кебек.
Күгәрепләр бетәр иде
Бу күңелләр җыр-моңсыз.
Әле дә Курамшалар бар!
Нишләр идек гармунсыз?..

БЕЗНЕҢ АВЫЛ СӨЙЛӘШЕ

Минем туган авылымда
Тумаган бер мин генә.
Тудырган, әдип иткән ул
Габдул Шәрәфине дә!

Мин дә инде үземне бер
Язучымын дип яшим.
Габдулла Шәрәфидә ул
Безнең авыл сөйләше!

Геройларын гел безнеңчә
Ул инде сөйләштерә!
Битаман телен, ичмаса,
Чын әдәбиләштерә!

Дөресрәк әйткән чакта,
Син, укучым, тор белеп:
Битаманлаштыра ул
Әдәби татар телен.

ҖЫРЧЫЛАРГА, ШӨКЕР, БАЙ ТАТАР!

Мирсәет Сөнгатуллинга

Нинди бетмәс моңнар бу татарда!
Татармы соң моңсыз торала?!
Җырчыларын аның тыңлаганда,
Актарыла бәгырь, турала.

«Тәфтиләү»ен аның, «Уел»ларын,
«Су буйлаб»ын, «Салкын чишмә»сен,
«Өнсә»ләрен аның тыңлаганда,
Моңланмыйча бәгырь нишләсен?!
Күңелкәйләр моңга сусаганда
Җырчылары, шөкер, бар аның.
Җырларында тирән моңнар аның,
Моңнарында сагыш, зар аның.
Тик җырлары аның елак түгел!
Дәртле моң бар татар җырында.
Яуга чыгып киткән чагында да
Җырлаган ул җиңү турында!
Нинди генә авыр заманда да
Моңлы татар җырсыз тормаган.
Ваһаповны, Илһам Шакировны,
Кудашеваларны тыңлаган.
Афзаловасы бар, Ильясовы,
Җырсыз торсынмыни, һай татар?!
Хәйдәре бар аның, Айдары бар –
Җырчыларга, шөкер, бай татар!
Нинди бетмәс моңнар бу татарда!
Татармы соң җырсыз торала?!
Инде шыксыз үтте дигәндә дә
Көннәремә җырлар урала.

ИЛАҺИ ИСЕМ ЙӨРТҮЧЕ ДУСТЫМА

Рәхмәт, бабам, мин дә синең дәвам,
Бер җырчысы нәсле Кукушкинның!
Равил Рахмани

Яхшы дуслар бик күп булмый,
Син – берсе шул азларның.
Җитмеш берен каршы алдың
Сиңа язган язларның.

Син муллалар нәселеннән.
Итагатьле ул халык.
Ерак китмәгән, синнән дә
Саркып тора муллалык.

Җиде буын бабаң мулла,
Кайсын алып баксаң да.
Әниең дә мулла кызы,
Мулла улы атаң да.

Мулла димәгән, тир түгеп,
Эшләп тапкан азыгын –
Кайсы аның тегермәнче,
Кайсы күмер казыган.

Галиулла атлы бабаң
Сәгатьче данын алган.
Күкеле сәгатьләр ясап,
Кукушкин булып калган.

Аллаһның туксан тугыз
Исеме арасыннан
«Рәхмәтле» дигән атын син
Үзеңә алдың – Рахман!*

---

* Мулла бабасына бояр кушкан Кукушкин фамилиясен үзгәртеп, Равил Фәйзерахман улы үзенә Рахмани фамилиясен алды.

Рафис КОРБАН

Кемнәрең юк иде, дөнья, Мин яшәгән заманда!..

Трай тибеп кенә йөрмәдек без,
Дәү әниләр безгә әйткәндәй.
Без нужаның ни икәнен белеп,
Эшләп үстек әткәй-әнкәйдәй.

Бәләкәйдән тәмен белеп үстек
Сызылып аккан маңгай тиренең.
Балдан татлы итеп ашый идек
Бер кыерчык ипи телемен.

Бәләкәйдән шулай эшләп үскәч,
Белеп үскәч тозлы тир тәмен,
Яхшы беләм ипи-ипекәйнең
Мин табынга ничек килгәнен.

Кай арада үсеп картайганбыз,
Әнкәй дә юк инде, әткәй дә.
Кинәт кенә ятим булып калдык,
Бер сүз белән генә әйткәндә.

Ә шулай да без бик бәхетләләр,
Бер сүз белән генә әйткәндә.
Без түгәрәк гаиләдә үстек,
Әнкәй дә бар иде, әткәй дә.

* * *

Кемнәрең юк иде, дөнья,
Кемнәрең сагындыра...
Равил Фәйзуллин

Кемнәрең юк иде, дөнья,
Мин яшәгән заманда!
Күптән югалган затларың
Сагындыра һаман да.

Урамнарны урап кайтсам,
Гел очрарлар кебек.
Таныш урам чатларыннан
Килеп чыгарлар кебек.

Алар да мине шулай ук
Сагынганнардыр кебек.
Алар да мине күрергә
Зар булганнардыр кебек.

Сагышларымны алам да,
Юнәләм урамнарга.
Табалмыйм яшьлек эзләрен,
Үзгәргән урамнар да.

Казан урамнары буйлап
Көн буе йөреп кайтам,
Югалттым дигән дусларның
Һәммәсен күреп кайтам.

Урамнары үзгәрсә дә,
Хатирәләрем исән.
Югалттым дигән дуслар да
Гел үзем белән икән!

* * *

Сизми дә калдым, яшьлегем
Үткән дә киткән икән.
Яшьлекнең миңа тиешле
Еллары беткән икән.

Ир уртасы дип йөртелер
Чагым да үткән икән.
Кай арада гомер үткән?
Картлыгым җиткән икән.

Туксан яшьлек бер карт көлде,
Шул булды юанычым:
«Син әле, ди, алтмыштагы
Яшь егет минем өчен!»

УЯНУ

Гыйнвар уртасы җитт(е)исә,
Әле бит кыш дип тормый,
Идән астында саклауга
Салган бәрәңге борный.

Борный, йомырканы тишкән
Тавык чебеше кебек.
Карында тибенеп яткан
Яралгы кеше кебек.

Яз килә! Ничек соң сөю
Уянмас йөрәгеңдә?!
Уята ул караңгыда
Яткан бәрәңгене дә!

Уята яз йокысыннан
Кар-буранлы мартны да.
Җир астына кереп ятар
Көне җиткән картны да!

Сөю уята йөрәктә,
Кодрәте зур язның!
Уятты менә мине дә –
Яратам, дип җыр яздым!

БЕР СҮЗ БЕЛӘН ГЕНӘ ӘЙТКӘНДӘ

Без түгәрәк гаиләдә үстек,
Әткәй дә бар иде, әнкәй дә.
Без түгәрәк бәхетлеләр идек,
Бер сүз белән генә әйткәндә.

ЯЗМЫШ ШУКЛЫКЛАРЫ

Хәйдәрдән

Борын заманда, кайсыдыр илдә
Яраткан патша йөрергә ауга.
Бер көтү яран һәм эт ияртеп,
Чыккан ул ауга, менеп атларга.

Ләззәт китерә Шәрыкта хәрам.
Быргы җыр суза хур кызы сыман.
Аучылар килә юрга атларда,
Тик тузып кала һавада тузан.

Тәүге уңыштан ярсып, аучылар
Алдылар атып шактый кош-киек.
Тик менә бәла – җәрәхәтләнде
Патша, кулына ялгыш ук тиеп.

Патшага һәрчак ялагай вәзир
Шулвакыт саксыз сүз ычкындырды:
«Күрергә язган булгандыр инде», –
Диеп, патшаны тынычландырды.

Бу сүздән патша: «Ах, әле шулай
Көләсеңме?!» – дип, кызды, кабарды.
Мескен вәзирне зинданга ябып
Куярга дигән әмер чыгарды.

...Икенче тапкыр падишаһ тагын
Аучылар белән чыкты сунарга.
Бу юлы алар юлыкты ауда
Кеше ашаучы юлбасарларга.

Һәм башкисәрләр сунарчыларның
Бөтенесен дә харап иттеләр.
Яралы кулын күреп, патшаның
Үзен кызганып, тими киттеләр.

Куркудан коты алынып, көчкә
Кайтып егылгач өенә, башта,
Аллага рәхмәт укып, зинданга
Вәзир янына килгән, ди, патша.

«Янам, – дигән ул, – оят утында,
Ялгыштым сине ябып зинданга.»
Һәм биргән сөйләп яраннарының
Харап булуын чыккач сунарга.

«Мине дә суеп ашарлар иде, –
Дигән, ди, вәзир, – зур рәхмәт инде,
Шулай зур хата ясавың өчен,
Мине зинданга япканың өчен».

Мамадыш районы Татарстанның төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Район үзәге – Мамадыш шәһәре. Районның мәйданы – республикадагы районнар арасында иң зуры – 2600 кв. км тәшкил итә. Халкы – 42550 кеше. Этник яктан караганда, шуның 76,3 процентын татарлар, 20,1 процентын руслар, калган 3, 6 процентын мари, удмурт, чуашлар тәшкил итә.

Халыкның 15806 сы – шәһәрдә, 26744 е авылларда яши. 130 авыл 28 авыл җирлегенә бүленгән. Район аша Чулман һәм Нократ елгалары ага. Район мәйданының 29,7 процентын урманнар биләп тора.

Мамадыш төбәге татар дөньясына күп санлы күренекле шәхесләр биргән як. Язучылар З.Мансуров, Ш.Мостафин, Р.Мөхәммәдиев, Р.Газизов, әтиле-уллы композитор Яруллиннар, җырчылар М.Галиев, Г.Ибушев, нәкышчы Н.Нәккаш исемнәрен генә атау да җитәдер.

ПАРИЖГА АВАЗДАШ МАМАДЫШ

АЗ-МАЗ ТАРИХ

Мамадышның туган якны өйрәнү музее 1800 елларда төзелгән сәүдәгәр йортына урнашкан. Музей директоры Минзилә ханым Садриева.

XI гасырда хәзерге Мамадыш районы территориясендә төньяк форпост сыйфатында Кирмән ныгытмасы урнашкан була. Башта анда бары тик гаскәр башлыклары гына яшәгән, соңрак ул зураеп, Ак Кирмән дигән болгар шәһәре үсеп чыга. Шәһәр 1236 елда монголлар һөҗүме нәтиҗәсендә җимерелә. Тарихчылар фикеренчә, болгар ханы белән Батый хан арасындагы килешү нәкъ менә монда, Кирмәнчектә төзелгән. Күпмедер вакыт үтү белән шәһәрлек яңадан төзелә һәм Алтын Урда чорында болгар дәүләтенең иң алга киткән шәһәрләренең берсенә әверелә. Борынгы Кирмәнчек болгар һәм рус кенәзлекләре белән Иран арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләрендә арадашчы үзәк булып торган. Кирмән шәһәрлеге 1396 елда рус кенәзе Юрий Суздальский тарафыннан җимерелә һәм башкача торгызылмый. Исән калган халкы төрле якка тарала һәм якындагы Рус, Урта һәм Кече Кирмән авылларына нигез сала.

Кирмән шәһәрлеге Мамадыш шәһәреннән Казан ягына таба 30 нчы чакрымда, Кирмән елгасының уң як ярында урнашкан. Хәзерге вакытта әлеге шәһәрлек калдыклары Федераль дәрәҗәдәге мәдәни мирас объекты булып санала. Ул республикадагы реконструкцияләнгән беренче агач шәһәрчек. Аның күзәтү манаралары бар, шәһәрне саклап шәһит киткән яугирләргә һәйкәл куелган. Якында гына җиде чишмәдән торган «Изге чишмәләр» комплексы җәйрәп ята, ерак түгел борынгы зират мәңгелек тормышы хакында искәртеп тора. Кыя тауның өстеннән үк агып төшүче 7 чишмәнең һәркайсы билгеле бер чирләрдән шифа бирә, диләр. Аларның шифасын эзләп монда ерак-ераклардан килүчеләр өзелми. Риваятьләргә караганда, монда ханлыкның өстендә кара болытлар куерганда Сөембикә ханбикә дә килгән һәм елап-елап гыйбадәт кылган. Тиздән, угылы белән үзен Мәскәүгә әсирлеккә озаткач, бу урында Күз чишмәсе бәреп чыккан, имеш. Бу чишмәнең суы күз авыруларынан сихәт бирә, дип ышаналар.

1552 елда Казан ханлыгы яулап алынгач, бу җирләр рус патшалыгы составына кертелә. Монда беренче итеп төзелгән рус авылы – Омара була. 1613 елның 3 июлендә Казан воеводалыгында Иске Мамадыш бистәсе урынына Троицкий–Мамадыш монастырь авылы төзелү турындагы грамота имзалана. Төбәктә бакыр эретү, май, күн, кирпеч, спирт заводлары, тукыма фабрикасы эшләгән.

● «Сон бизәкләре» фольклор ансамбле.

Мамадышның туган якны өйрәнү музеенда Кирмәнчектә табылган 100 дән артык экспонат бар: Алтын Урда чүлмәкләре, алтын тәңкәләр, Коръән савыты, кашлы йөзекләр, бизәнү әйберләре... Музейда өстәл тутырып яткан саллы албомнар да игътибарны җәлеп итте. 28 авыл җирлегенең һәркайсы үз авылларының тарихларын язып, шәхесләрен барлап, альбомнар алып килгән. Аларны берләштереп, 2 томда эшләтеп алганнар. Халкыбыз тарихы менә шундый авыллар тарихыннан берәмтекләп җыелуын истә тотсак, бу – олы бәягә лаеклы гамәл.

ДОГАЛЫ ҖЫЕН

Кирмәнчек шәһәрлегендә ике җәй рәттән Кирмән җыенын үткәргәннәр. Шәһәрлеккә килә торган юл салганнар, чишмәләрне ялт итеп төзекләндереп куйганнар. Җыенга район халкы гына түгел, күп санлы кунаклар да җыелган. Быелгы Кирмән җыенына «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы форумына җыелган ханымнар да кайткан. Җыенда татар фольклор ансамбльләре чыгыш ясый, мөнәҗәтләр яңгырый. Җыенга татарча-мөселманча киемнәрдән килүне шарт итеп куйганнар. Халык пылаулар пешерә, җәмәгать намазы укый. Осталарның кул эшләреннән – күргәзмәләр, балалар өчен милли уеннар, ярышлар оештырганнар.

ҺӘР МИЛЛӘТНЕ ХАКЛАП

Мамадышта җирле туризмны рәхәтләндереп үстерәләр. Быел гына су юлы белән 7 теплоход турист килгән. Аларның игътибарларын җәлеп итү, кызыксындыру өчен әллә ничә проект, төрле маршрутлар эшләнгән. Шулар арасында «Бер юлда биш мәдәният» дигәне иң кызыклысы булып тоелды. Бу проект кунакларны Мамадыш төбәгендә гомер сөрүче төп биш халык белән таныштыруны максат итә. Маршрут биш авыл аша үтә: Түбән Ушмы – татар, Зур Шия – мари, Красная Горка – рус,



● Кече Сондә якташ композиторларны зурлап сквер ачканнар.



● Ярулиннарның төп нигезендәге сквер.



● Яруллиннар музее ядкяре.

● Кече Сондәге Яруллиннар музее.

● Яруллиннар музеенда.

● Гүзәлия ханым үз музеенда.

Җөри – керәшен, Пойкино – удмурт авылы. Һәр авылда туктап, кунаклар әлеге халыкларның мәдәнияте, традицияләре белән таныша, музыкаларын тыңлый, йолаларын карый. Авылның барлыкка килү тарихын да сөйлиләр. Аннары кунакларны милли ризыклар белән сыйлыйлар, туган телләрендә биеп-җырлап күңелләрен ачалар. Бергәләп истәлеккә сувенирлар ясыйлар.

Күпләр Мамадышны «керәшеннәр башкаласы» – Җөри авылы аша ишетеп беләдер. Чөнки монда 25 ел рәттән ел саен республикакүләм Питрау бәйрәме уза. Җөридә Питрау тарихы музеен да эшләп киләләр. Гомумән, Мамадышта тарихка бәйле һәр ядкярне кадерләп, барлап торалар, үз тарихлары, шәхесләре белән горурланалар. Туган якны өйрәнү музееннан чыкканда, күршедәге тагын бер борынгы бинаны реставрацияләп ятуларын күрдек. Анысы да музей булачак, диделәр. Шаһиәхмәтов дигән сәүдәгәр йортында Әниләр музее урнашачак икән. Урта Кирмән авылында яшәгән Фатиха ханым Әхмәдиева Бөек Ватан сугышында 9 баласын югалта. Район хакиме А.Иванов татар хатынының фаҗигале язмышын белгәч, шушы музейны ачарга ниятли. Әниләр музееның инде тәүге экспонатлары да әзер: оныгы Марзыя апа Фатиха ханымның 8 бизәкле сөлгесен һәм Коръән китабын бүләк иткән.

ЯРУЛЛИННАР АВЫЛЫ

Мамадыш халкы татар дөньясына күренекле композитор, беренче татар балетын иҗат иткән Фәрит Яруллин, аның әтисе – талантлы композитор Заһидулла Яруллин һәм нәсел дәвамчылары булган Мирсәет ага Яруллин белән горурлана. Кече Сон авылында Яруллиннарның музее да эшли. Яруллиннарның төп йортында 90 нчы елларда ук бик шәп музей ачкан булалар, тик ул берничә ел гына эшләп кала – агач йорт янгында янып бетә, бик күп кадерле экспонатлар, ядкярләр юкка чыга. Аннары Яруллиннар музееен мәктәптә оештырырга тырышып, бүлмә бирәләр, тик ул оешып ук җитә алмый. Ниһаять, 2014 елда якташлар ныклап алына һәм авылдагы 1850 елда төзелгән тарихи мәдрәсә бинасын музей өчен дип төзекләндерә башлыйлар. Бина инкыйлабтан соң 70 елларга кадәр мәктәп булып хезмәт иткән, аннары шактый вакыт буш торган. Мәдрәсә бинасын диварларын гына калдырып сүтәләр, чистарталар һәм яңадан төзиләр. Бу эшләрнең башында авыл җирлеге башлыгы Мансур Сәләхов тора. Иске бинаны сүткәндә балалар да ярдәм итә, читтән кеше чакырмыйча, авылдашлар көче белән төзиләр. Акчасын халык та җыя, төзүдә бюджет өлкәсе хезмәткәрләре дә көч куя. Хәзер музейда композитор Яруллиннар, аларның нәселе, гомумән, шул чорлар тормышы хакында әллә нихәтле мәгълүмат тупланган, экспозицияләр төзелгән. Ә композиторларның төп йорты булган урында бүген Яруллиннар исемендәге сквер эшләп куйганнар. Авыл балалары бу музей мохитендә, скверда булып, үзләре дә күңелләре белән серле сәнгать дөньясына тартыладыр дип ышанасы килә. Тик авылда балалар саны аз булуы гына күңелгә шом сала. Тугызьеллык татар мәктәбендә нибары 20 бала укып йөри… Югыйсә, эшлим дигән кешегә эше да бар. Әйтик, фермер Рифат Мотыйгуллин эшкә вахта автобусы белән йөртә, хезмәт хакы да начар түгел – 30 меңнән дә ким түләми, диләр. Тик яшьләр никтер авылда төпләнеп калырга теләми шул.

«СОН БИЗӘКЛӘРЕ»

Күршедәге Югары Сонда данлыклы «Сон бизәкләре» халык фольклор коллективы эшли. Ансамбль 1984 елда ук оешкан, ә «халык» исеменә узган ел лаек булганнар. Аны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлсинә ханым Фәйзетдинова җитәкли. Монда җырлап-биеп йөрүче 18 ханым һәр бәйрәмне үткәрә. Татарстанның алар барып чыгыш ясамаган бер почмагы да калмаган. Азнакайдагы Чатыр Тау җыенына, Болгардагы Ага-Базарга, «Түгәрәк уен»га, «Уйнагыз, гармуннар»га ел саен бара. Бу коллективның үзенчәлеге шунда: алар һәр чыгышларының сценариен үзләре яза, каяндыр ишеткән такмаклар, җырларны түгел, ә сүзләрен дә, көен дә үз авыл кешеләре язган әсәрләрне башкара. Гүзәлия апа өздереп тальянда уйный, башкалары җырлый да, бии дә. Элек авылда 25 ел буе сәнгать мәктәбенең филиалы эшләгән, Гүзәлия ханым шунда укыткан. Югары Сонда 360 лап кеше яши, ә тугызьеллык мәктәптәге балалар саны тагын да азрак – нибары 11, бакчага йөрүчеләре – өчәү… Халык балаларын авылда калдырмаска тырыша, диләр. Авыл картая… Коллективка йөрүчеләр дә – апалар, әбиләр. Авылның үзендә чынлап та эш юк, ә эшлим дигән кешене вахта белән күрше авылга йөртәләр икән.

КЕЛӘТТӘГЕ МУЗЕЙ

Иҗади күңелле, башкалардан аерылып торган бай күңелле кешеләр һәр районда очрый. Тукай юкка гына халык зур ул, көчле ул, димәгән. Мамадышта да шундый халык таланты белән көрешергә насыйп булды. Гүзәлия ханым Гобәйдуллина – кулларыннан гөл тама торган чигү остасы. Гомере буе китапханәдә эшләгән, нинди генә чара уздырсалар да, аны күз нурлары түгеп чигелгән эшләнмәләре белән бизәгән, баеткан. Лаеклы ялга чыккач та тынгысыз күңелле ханым тик

● Музей күренеше.

ятмаган: Мамадыш мәдрәсәсендә укып чыккан, аннары үз ишегалдындагы келәттә… музей ачып җибәргән! Нәрсә генә юк анда! Борынгы эш кораллары, җиһазлар, киемнәр, совет чоры әсбаплары… «Махсус җыймадым. Электән үзебездә сакланып килгән ядкярләр, ике як әниләрнең чоланнарында яткан байлыкларны кузгаттым», – ди Гүзәлия апа. Билгеле бер тәртиптә тезеп, ярлыклар урнаштырган. Нәтиҗәдә бакча, мәктәп балалары өчен мул мәгълүмат бирерлек музей барлыкка килгән. Әйтик, монда килеп үз күзләре белән күрмәсә, чигүле аяк чолгавының яки май яза торган кул машинасының нәрсә икәнен мәңге белмәячәк бит хәзерге балалар. Ә биредә әби-бабаларының тормышы, көнкүреше белән таныштырырлык тарихи байлыкларның хисабы юк…

МАМАДЫШТА ТЕАТР БУЛАЧАК!

Шулай дип ышанып әйтергә буладыр, чөнки бүген районда бу идея белән янып йөрүчеләр күп. Мамадыш хакиме Анатолий Иванов та шушы юлда тырышлык күрсәтүчеләрне хуплап, өметләндереп тора. Мамадыш халык театрының тарихы

● Гүзәлия ханымның иҗат җимешләре.

1918 елларга ук барып тоташа. Төрле чорларны кичкән ул, тик татар кешесе беркайчан да театрга тартылудан тукталмаган. Инде профессионал театр булырак ачылырга берничә адым гына калгач, пандемия афәте башлана да, идея артка чигенә. Җыелган артистлар да тарала. Аларны яңадан тупларга, иҗат ялкыны белән дәртләндерергә, яңа спектакльләр чыгарып, Мамадышка татар театрының кирәклеген кабат исбатларга кирәк. Бүген бу эш белән Марат Баязитов шөгыльләнә. Ул үзе дә профессиональ актер, башкала театрларында эшләгән кеше, хатыны Зөлфирә Дәүләтшина да – актриса. Марат әфәнде – яңа татар театрының Мамадышка милли рух өрәчәгенә, аның кирәклегенә ихластан ышанган иҗат иясе. Күнегелгән тормышын, башкала шау-шуын ташлап, монда кайтып төпләнүе дә юкка түгелдер. Бүген Мамадыш халык театры район үзәгендәге мәдәният йортына сыенган. Тиздән аның иркенрәк йортка күченү, ә Мамадышның барлык чын мәдәни шәһәрләргә хас рәвештә, профессиональ театрлы булу өмете бар…

Эльмира СИРАҖИ.

Мәдәни җомга
3 ноябрь
№43, 2022

Ак калфак

Гөлүсә БАТТАЛОВА

Гайшәбикә карчыкның тирләп-пешеп эчкән мәтрүшкәле-сөтле чәенең тәмен кинәт кенә телгә килгән телефон тавышы бозды. Әллә нигә бер чылтыраганга каушап киттеме, җиңелчә калтыранган кулы белән трубкага үрелде:

– Әлү… Әлү?..

– Алло, әни! Нихәл?

– Кызым, Люция, синме бу? Ару гына торам әле. Үзең ничек, балам?

– Ничек, ничек?! Чәчләр агара монда! Синең тәрбияң җимешләрен бирә башлады. Рушаның әнә, детдом йолкышын ияртеп кайткан. Пырынлатып куып чыгардым! Алай-болай сиңа кайтып күренсәләр, бусагаңнан да атлатасы булма, ишетсен колагың!

– Тукта, кызым, берни аңламадым. Ипләбрәк сөйлә әле. Рушан улым нишләгән дисең?

– Нишләсен, өйләнәм дип, детдомда үскән бер салам сыйракны алып кайткан. Синең белән таныштырасым килә, әни, дигән була, юньсез. Мин аны бетле хәерчеләр өчен үстермәдем. Өйләнә икән, әнә, хәллерәк гаиләдән кыз тапсын. Тиен санап, очын-очка ялгап яшәүдән болай да гарык. Ярар, әни, син мине ишеттең. Бусагадан да кертәсе булма, кара аны… Иллә дә мәгәр, түрењә меңгезеп утыртсаң шуларны, үлсәң дә, сыңар аягымның берсен дә атламыйм!

Сөйләшү ничек кинәт башланды, шулай өзелде дә. Гайшәбикә карчык берара уйларының җеп очын табалмый утырды. Рушан өйләнәм дип әйтә диме? Бәрәкалла, егет кешенең вакытында башлы-күзле булуы әйбәт. Яше барган саен, күңеле-башы үзгәреп, бөтенләй өйләнми калса, ни әйтерсең? Авылда буйдакларның исәбе-чуты юк.

Детдом баласы диде диюен дә, килен буласы кешенең исемен дә әйтмәде. Әстәгъфирулла, маржафәлән генә була күрмәсен!

Әнә күрше Раузалиянең алма бөртеге кебек кызы тотты да урыс егетенә чыгып куйды. Ата-анасы теше-тырнагы белән каршы торып карадылар да, тик кая ул! Барам булгач барам – бетте китте. Әй, татар урыска барса да, урысны алса да, урыс үстерә диюләре дөрес инде ул. Күршегә оныклар кайта хәзер, кемнән кем туганы исемнәреннән үк билгеле: малай – Захар, кыз – София. Раузалия берсенә Зәкәр, икенчесенә Суфия дип дәшә дәшүен дә, тик менә бер кәлимә татарча белмәгән оныкларның алай гына татар буласы килми шул.

Соңгы кайтуларында муеннарына тәре асканнар, кая барыйм дип, тәгәри-тәгәри елады күршекәе. Йә, Аллам, ни юрап утыра соң әле, маржа түгелме имеш, авызыннан җил алсын! Рушан улының күзе ачык, бер дигән кыз баладыр әле, Ходай кушсын. Люциясенең пырдымсызлануы бүген генә түгел. Бала-баладан әллә ниткән холыксыз, мамыксыз булып үсте шул. Әллә тәрбия, әллә җан җылысы җитмәде. И, кая җитсен! Бала туып, ае тулмады, Хәлиулласы китеп барды. Йөрәк өянәге, диделәр.

Улын җир куенына салган кайнанасы бу кайгыны күтәрә алмады, ярты елдан гүр иясе булды. Тәртә башында япа-ялгызы торып калгач, нишли аласың, тормышны җигелеп тартты – көн эшләде, төн эшләде. Бер караңгыдан икенче караңгыга тиклем колхоз эшендә. Әле ярый, ул елларда авылда яслесе ачылды. Сабыеның ничек тәпи киткәнен дә, сөйләшә башлаганын да хәтерләми.

Люциясен башта ясле, аннан соң мәктәптә октябрят, пионер дружинасы, быргы-барабан тәрбияләде. Әни дип, авыл дип өзелеп тормады, сигезне бетерүгә шәһәр ягын каерды. Сагынмады, авылга кайтуны бар дип тә белмәде. Акча-мазар, тегесен-монысын җибәрүне сораган хатлары гына килеп торды. Дәү укуларда укыйдыр, шуңа вакыты юктыр дип, үзен-үзе юатып яшәп ятканда, Люциясе борын төбенә җиткән корсагы белән авылга кайтып утырды. «Ай, балам, тормышка чыктыңмы, кияү кеше кайда, никахны кайчан укыттыгыз?» – ише сорауларына җавап һәрвакыттагыча коры иде: «Нинди никах? Синең искелек калдыгың кемгә кирәк? Комсомол туе ясадык. Радик Казахстан якларына эшкә китте. Общагага бала белән кертмиләр, монда гына табам». Кызының сүзләренә ул чакта ни көенергә, ни сөенергә белмәде…

Тупырдап торган ир бала тапты Люция. Руслан дип исем кушам дигән кызына бу юлы Гайшәбикә каты торды. «Сәвиткә ияреп, сиңа Люция кушканым да җиткән, Руслан түгел, Рушан булсын. Бик мәгънәле, бик матур исем бит», – дигәч, кызы каршы килмәде, бала туып, атна-ун көн үтүгә, мең төрле сәбәп табып, шәһәренә китеп тә барды. «Әлегә Рушанны калдырам, аннан күз күрер. Син хәзер пенсиядә, эшең юк, бер баланы гына карарсың, миңа тормышымны җайларга кирәк», – Люциясе әнисенең дә, баласының да алдагы көнен әнә шулай җайлы гына хәл итте дә куйды.

Исеме җисеменә туры килде нарасыйның, Гайшәбикәнең бертөрле аккан тормышына якты нур өстәлде. Күкрәк сөтеннән аерылды дип борчылган иде, урам аша күршесе Әминә үз баласы белән бергә Рушанны да имезергә ризалашты. Кайчандыр кызына бирә алмаган бар күңелен, йөрәк җылысын оныгына багышлады Гайшәбикә. Люциясе анда-санда бер кайтып киткәләде, малай авылда үсте. Әбием дип өзелеп торса да, әнисен бик сагына иде. Әти кешене бөтенләй белмәде. Ахрысы, ул Радик дигәннәре бөтенләй юкка чыккан иде.

Әбисен сөендереп, Рушан әйбәт укыды, тәртипле-тәрбияле егетләр исәбендә йөрде. Мәктәпне тәмамлауга, ике дә уйламый, армиягә китте. Бер елдан хезмәтен тәмамлап, җилкәләре киңәеп, буйлары үсеп, көрәеп кайтып та төште. «Агрономлыкка укырга керәм, әби, кулга диплом алуга, синең яныңа кайтам», – дип елмайган оныгына карап, күзләре дымланды Гайшәбикә карчыкның. Улының шәһәргә укырга керүенә, үзе янына яшәргә килүенә Люция генә бик шатланмады. Кем әйтмешли, пирчәткә урынына ирләрен алыштырган хатын өчен малай ашка төшкән таракан кебек булды. Нәкъ менә шуның өчен дә фатирлы бер кыз табып, үзе яныннан ничек тә тизрәк чыгарып җибәрү иде уе. Ә монда менә ничек килеп чыкты.

Капка шыгырдаган тавышка Гайшәбикә карчык уйларыннан айнып китте. Ул арада өй ишеге ачылды да, һәрвакыттагыча балкып, Рушан килеп керде. «Исән-сау гына тордыңмы, әби?» Оныгы артына посып диярлек бусагадан атлаган чандыр буйлы кыз бала Гайшәбикә карчыкның күзләренә карап, исәнмесез дигәндәй баш селкеде дә, керфекләрен аска төшерде.

– Кайттыгызмы, балалар, нишләп әле ишек төбендә генә торасыз? Рушан, улым, әйдәгез әле, узыгыз әле, – дип, каушавын яшерергә тырышты карчык.

– Әби, таныш бул, минем булачак тормыш иптәшем – Айсылу.

– Исәнме, әби…

– Сөбханалла, үзебезнең татар кызы икән бит, күрешик, савап булсын! – дип, шатлыгын яшермәде Гайшәбикә әби.

Ул да түгел, йөгереп диярлек барып, чәйнеген плитәгә куйды, өстәл япмасын җыеп алып, табын хәстәрли башлады.

–Әби, болар Казан күчтәнәчләре иде, аз булса да, күп итеп кабул итеп ал инде, – Айсылуның йомшак кына ягымлы тавышы Гайшәбикә әбинең күңеленә сары май булып ятты.

– И, мәшәкатьләнмәскә иде, кызым, Алланың рәхмәте яусын, урыны кимесен, хәзинәсе артсын!

Гөрләшә-гөрләшә чәй эчтеләр. Айсылу да, әллә ни күп сөйләшмәсә дә, күптәнге танышлары янында утыргандай, ихлас елмаеп, әңгәмәгә кушылып-кушылып алды. Чәй тәмам булуга, Рушан йорт тирәсенә чыгып китте. Айсылу җитез генә савыт-сабалар юарга, өстәл җыештырырга кереште. Гайшәбикә әби, үз эшләре белән мәшгуль булгандай, сиздерми генә, яратып, Айсылуны күзәтте.

– Әби, хәзер нәрсә эшлик, нинди эш бар? – дип сорады Айсылу, соңгы чынаягын сөртеп, шкафка урнаштырганнан соң.

– Кичкә аш куйыйк, кызым, токмач җәеп, кисеп алырбыз.

– Мин токмач җәя белмим шул…

– Борчылма, балам, берәү дә белеп тумый. Миңа да кайчандыр кемдер өйрәткән инде аны.

– Ә син мине өйрәтерсеңме соң?

– Безгә – карт-корыга өйрәтергә генә куш! Өйрәтмимме соң!

– Нәрсәдән башлыйбыз, әби?

– Иң әүвәл, кызым, бисмиллаңы әйтик, башыңа менә шушы ак яулыкны бәйлә. Кулларны юып алыйк. Безнең куна тактасы белән уклауның урыны бирегә, әйдә, эшкә тотыныйк. Бисмилләһир-рахмәнир-рахиим.

Гайшәбикә әби белгәнен өйрәтер кеше табылганга, Айсылу өйрәтүче булганга сөенә-сөенә эшкә керештеләр. Эш арасында Гайшәбикә карчык алай да сорыйсы итте:

– Кай яклардан син, кызым? Кайсы районда туып-үстең, үзебезнең Татарстанныкымы диюем инде.

Шул сорауны гына көткәндәй, Айсылу ачылып китте:

– Мин биш яшемнән балалар йортында үстем. Әти-әнием Сарман ягыннан булганнар. Аларны бөтенләй хәтерләмим. Юл һәлакәтенә очраганнар, миңа яшь тә тулмаган булган. Әтием ягыннан әбием тәрбияләде мине, биш яшем тулганда ул да үлеп китте. Ә әниемнең әти-әнисе күптән вафат. Башка якын туганнарыбыз юк, мине балалар йортына урнаштырдылар. Мәктәпне бетердем, бер ел эшләп, укытучы дипломы алдым. Балалар укытам.

– Балачагың хәсрәтле булган икән, кызым, инде алдагы көнегез куанычлы, бәрәкәтле булсын…

– Рәхмәт… Әби, токмачны шулай киссәм ярыймы, калын булмыймы?

– Ярамаган кая, күргәзмәгә куярлык булган болар, күз тимәсен! Мин борынгырак кеше шул инде, кибет токмачын өнәп бетермим, үзең җәйгәнгә җитми инде. Әле беркөнне гәҗиттән укыдым, имеш, уклау тәгәрәткәндә уч төбенә массаж да ясала икән. Менәтрәк, массаж ясату модалы диләр, без кемнән ким, шулай бит кызым? – дип көлемсерәде Гайшәбикә карчык.

– Борынгылар белми эшләмәгәндәр, әнә бит син нинди матур, кулларың да шундый йомшак!

(Дәвамы киләсе санда).

Дөньяны шаулаткан татар



● Р. Нуриев филармония каршында.

● Р. Нуриев «Валентино» фильмында.

(Дәвамы. Башы 41, 42 нче саннарда).

Биюченең туганнары әйтүенчә, паралич сугып урын өстенә калган ана соңрак үз улын тануы хакында белдерткән. Без аның иреннәрен ничек кымшатуына карап ук аңладык дигән алар. Ләкин Рудольф моңа ышанмаган. Ә менә чирләп, урын өстендә ятучы туганы Лилия энесен шундук таныган. Биюче табынга калмаган. Барысы да аның белән ничектер кыенсынып кына сөйләшкән. Алар нәрсә турында сөйләшергә дә белмәгән.

Биюче 1991 елда Марго Фонтейнның үлемен дә авыр кичергән. Ул Маргога дарулар өчен күп акчалар сарыф иткән. Заманында Маргоның да үзенә бик булышканлыгын онытмаган. «Беләсеңме Марго ничек үлде? Бер ялгызы калды, аны берәү дә искә алмады. Безнең барыбыз белән дә шулай булачак: исәптән сызып ташлаячаклар, шуның белән тәмам», – диде. Нуриев шуннан алда гына финанс эшләрен алып баручы Горлински белән хушлашты. Рудольф үз матди хәленең нинди дәрәҗәдә икәнен белми дә калды. «Мин акчаларымның кайда икәнен тулысынча аңламыйм. Миңа ярдәм кирәк, ләкин хәзер беркемгә дә ышанырга ярамый...» Рудольфны кысканнан-кыса барган түгәрәк хасил булган кебек иде. Безнең акрын һәм авыр итеп телефоннан сөйләшкән вакытларыбызда аның аруы телефон аша миңа күчә кебек тоела башлады – мин анда өмет сүрелү ноталары пәйда булуын һәм язмышка буйсынуын сизә башладым», – дип искә алган Голландия артисты, хореограф, Нидерланд театры җитәкчесе Руди ван Данциг үзенең «Нуриевне искә алып. Комета эзе» китабында.

Арган, чирдән тәмам талчыккан Р.Нуриев 1990 елдан соң да биюдән туктамый. Ул Куба Милли балеты белән, Неаполь балеты белән дә бии, аның өчен махсус язылган балетларда да... Төньяк Америка, Германия, Испания, Италия буенча турне үткәрә. 52 яшьлек шәхес өчен яраткан һөнәре – тормыш мәгънәсе. Һәр тамаша алкышлар белән тәмамлана.

Әмма аның бар көченә бии алмавын ошатмаучылар да пәйда була. Сәхнә артында, грим бүлмәсендә тере мәеттәй утырып торган биюче сәхнәгә чыгып бии башлауга ук һәрчак үзгәрә. Аның бар бәхете – биюдә! Балет сәнгате тарихын яхшы белүчеләрнең исендә: ул 1964 елны Вена опера театрында төп рольне Марго Фонтейн белән башкарды. «Аккош күле» балетын биеп бетергәч, сәхнә пәрдәләре 89 тапкыр күтәрелде, М.Фонтейнны һәм Р.Нуриевне тамашачылар сәхнәгә 89 тапкыр алкышлап чакырдылар. Гаҗәеп театраль рекорд!

Ләкин язмыш аяусыз... 1991 елның сентябрендә Бухарестагы чыгышлары вакытында биюче бөерләре авыртуын сизә. Аңа Вена хастаханәсендә операция ясыйлар. Ул тәнендә пластик капчык була торып та биюен дәвам итә. Өч айдан соң ул инде Австриядәге гастрольләрдә. «Фавнның төштән соң йокысы» спектакле тәмамлангач: «Мин әйтерсең кургаш белән тулдым», – ди. Аңа, чыннан да, бик читен була. Әмма заллар тулы, халыкның Нуриев биюен күрәсе килә. 1992 елның 28 февралендә Р.Нуриев Будапештта, «Кристофоро» балетында Фәрештә партиясен бии. Иң соңгы тапкыр. 53 яшендә.

Бер көн эчендә гасыр каһарманына әйләнә алган, теләсә кайсы тамашачыларны сокландырган, Көнбатышка илебезнең классик балет сәнгате кануннарын керткән, спектакльләренә кызыксыну уяткан Рудольф Хәмит улы өчен иң авыр еллар, билгеле, директор вазыйфаларын үтәгән чоры. 1983-1989 елларда ул Парижның «Гранд-опера» балет труппасы директоры булып эшли. Килешү буенча Нуриев өч хезмәт хакы ала: балет артисты, хореограф һәм труппа директоры буларак, дип яза Отис Стюарт үзенең «Рудольф Нуриев» китабында. «Бер ел эчендә 150 мең доллар. Рудольф бу постка ризалык биреп, нәрсәгә алынуын бик яхшы аңлый. Биредә ул биегән дә, 1975 елда «Баядерка»дан «Шәүләләр»не дә куйган. Әлеге театр бюрократиясе белән күпләргә мәгълүм, театр төрле затларның сәяси интригалары мишене булып та тора. Чынлыкта, «Гранд-опера» – ул гигант милли корпорация (Нуриев анда килгәч тә, әлеге труппа Франция тарафыннан балетка бүлеп бирелә торган акчаның яртысын – 12 млн доллар ала). Анда 150 артист эшли, һәм төрле тармактагы профсоюзлар челтәре бар». Нуриев труппаны үзенеке булачак дип кузаллый. Әмма биредәге кануннар буенча бу мөмкин түгел. Ул бары тик труппа директоры гына, ихтирамга ия бер месье... Биредә бары генераль директор, президент кына хуҗа... Бары да шуларга буйсына. «Р.Нуриев берничә тапкыр үз теләге белән китергә теләп тә мөрәҗәгать итте», – диячәк труппа артисты П.Дюпон. Ул нигездә рус классикасын куя, Чайковскийны... Төп рольләрне дә яшь биючеләргә бирергә омтыла. Аларны «йолдыз» дәрәҗәсенә күтәрә. Труппада аны диктатор дип атыйлар, директор эшеннән гел гаеп эзлиләр. Ике ел эшләгәч ул моны үзенчә аңлата: «Мине кинәт кенә ниндидер сюрреалистик дөньяга тыктылар. Озак вакыт сәркатибем дә, телефоным да, хәтта урындыгым да булмады. «Гранд-опера» үз гореф-гадәтләренә ия. Сез биредәге бар нәрсәгә бюрократия сеңгәнен тоемлыйсыз». Ул, билгеле, кызып китеп, тавышын күтәреп сөйләшә, тупас та була, тозлы-борычлы сүзләр әйтүдән дә тартынмый. Труппа артистлары аңа каршы забастовка да оештырырга омтыла, тик бары бер каршы сүз әйтмиләр. Чөнки шушы җитәкчелектә генә труппа уңышсыз коллективтан иң уңышлы труппага әйләнүен бик яхшы белә. Рудольф Хәмит улының уңышларын яңадан тусалар да кабатлый алмаячакларын да аңлыйлар. Гомер булмаган батырчылык: ул, архитектор чакыртып, Гранье сараендагы зур репертиция залын бүлгәли, аны уңайлы булырлык итеп үзгәртерә. Президент Ф.Миттеран да аңа еш мөрәҗәгать итә, мәдәният министрлыгы да. Бу эш урынында аңа кадәр дә, аннан соң да рәттән алты ел эшләүче табылмаячак. Җитәкче буларак, Рудольф Хәмит улы шулкадәр катгый, билгеле, ул русча каты сүгенә дә, әрли дә, мактый да... Кемнәрдер аның режессурасын бөтенләй ошатмый. Әмма шунысы да бар: спектакль тәмамланып, артистлар баш игәч, пәрдә ябыла. Халыкның тараласы да килми, алкышлар тынмый.

Үземне начар хис итәм дип, 1983 елда табибләргә мөрәҗәгать итсә дә, кан анализы анда яман чир булуын күрсәтми. Нуриев үзе дә бу чиргә ышанмый. Әмма 1984 елда инде бары да аңлашыла. Аның тормышы теләсә кайсы көнне үлем белән тәмамлана алачак. Ләкин СПИД хакындагы мәгълүматлар җәмгыятьтә аз, һәм күпләр чир йоктыручыларның уннан берсе генә җитди чирләп китә ала, дип уйлый. Нуриев тә борчыла, әмма тыныч була. Һәр көн веналарына тәҗрибә этабындагы даруны кадата. 4-5 ай буе укол кадау биюләренә киртә булмый. Аннары атнасына 3-4 укол кадату гына кала. Нуриев – яхшы физик формада, үзен начар хис итми. 1985 елда берничә тапкыр бронхит белән авырса да бии. Әмма 1988 елда ул инде табибтән башка яңа, ләкин авыр препарат кабул итә башлауны таләп итә, тик ул аны үзе генә даими рәвештә кулланмый. 1988 елда 50 яшьлек юбилеен уздыра. Ул хәтта грипп белән чирләсә дә, биергә чыга. Бию – аның өчен һава кебек! Бинтлар белән уралып беткән аякларын да, йөзе агаруын да, аның югалтуларын да, биеп бетергәч, сәхнә артында авып китүләрен дә, аяклары тотмас хәлгә җитүен дә күрәләр. Әмма ул бии. Никадәр авыр һәм читен булса да, һәр бер паны тиешенчә камиллектә башкара.

1989 елда Америка буенча турне, аннары Германия гастроле, аннары Швейцария... 1989 елда «Гранд-опера» җитәкчелегеннән китсә дә, мәшһүр шәхес бу театрда даими килешүләр төзү хокукына ия баш хореограф булып кала. Әмма аның күңеле төшкән, ул бу труппа өчен нинди уңай гамәлләр кылганын бик яхшы белә, ә алар... рәхмәтсез. «Король һәм мин» мюзиклында катнашырга риза була, анда хәтта җырлый да. Тугыз ай барган тамашаны тәнкыйтьләсәләр дә, әлеге мюзикл барыбер табыш китерә. Аннары «Нуриев һәм аның дуслары» антипризасы белән Мексиканың унике каласында, АКШта, Канадада чыгышлар ясый башлый...

1990 елда ул үзенең инде бии алмавын таныгач, 1991 елның мартында күптәнге дусты, Вена музыка академиясе профессоры В.Хубнердан дирижерлык белемнәрен өйрәнә башлый. Чөнки аңа син бит дирижерлык итә алачаксың дип әйтүчеләр була. Хәтта 1988 елда ук. Өч айдан соң ул Венаның Аугсбург сараенда дирижерлык итә. Һәм гомумән киң репертуар буенча дирижерлык итә башлый. Австрия, Италия, Греция, Франция, АКШта... Әмма чир аза, 1992 елның апрелендә – тагын операция. Монысы перикардит белән бәйле. Ул тиз терелә һәм тагын эшенә кайтып, Нью-Йорктагы «Метрополитен-опера»да «Ромео һәм Джульетта»га дирижерлык итә. «3 сәгать буе дирижерлык пульты артында, балет өчен тулысынча җавап биреп, хезмәт кую – моңа һәркем җөрьәт итә алмас иде», – ди башка дирижерлар, аны бик мактап. «Бу физик яктан да, рухи яктан да авыр. Темп дөрес булырга, барысы да үлчәнеп эшләнергә тиеш, югыйсә музыкантлар артистларның аякларын йолкыячак», – ди Америка балет театрының баш дирижеры Ч.Баркер.

1992 елда ул Казанга да чакырыла, «Щелкунчик» һәм «Ромео һәм Джульетта»га дирижерлык итә. «Тамаша тәмамлангач, алкышлар ишеткәч, ул үзен шулкадәр бәхетле итеп хис итте!» – дип искә ала Казан опера һәм балет театры җитәкчелеге. Биредә ул туганнан туганы Лиада Вәлиулла кызы Хөсәеновалы да күреп куана һәм аңа үзендә әтисенең бер фотосы да булмавын әйтеп, әтисенең берничә фотосурәтен дә сорап ала. Казаннан фотолар алып китүен иң зур бүләккә саный.

1992 елда биюче «Гранд-опера»да күңеленә якын «Баядерка»ның куя. 8 октябрьда, аның премьерасында үзе дә була. Бу – аның өчен шатлыклы да, моңсу да көн. Ярты төнгә кадәр барган репетицияләр дә талчыктырган, табибе – янәшәдә генә. Сәхнәгә чәчәк бәйләмнәре оча, халык «Афәрин!» дип алкышлый. Сәхнәдә инде биючеләргә таянып кына басып торган талантлы биючене, хореографны күргәч, аның көннәре санаулы икәнен һәркем аңлый. Нуриевкә сәхнәдә ун минут басып тору да җәфа, ә тантана дәвам итә. Ул креслога утыра. Мәдәният министры Жак Ланг аңа Сәнгать һәм Әдәбият Командоры орденын тапшыра. Тантанадан соңгы табын артында ул инде озаклап утырып тормый, кайтып китә. Шатлыктан дусларына Санкт-Петербургта балет мәктәбе ачарга теләве хакында да әйтә. Ул әле яңа балетлар куячагы, тагын дирижерлык итәчәге хакында хыяллана...

(Дәвамы киләсе санда).

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
3 ноябрь
№43, 2022

МУРМАНСК –

Әле шимбә кичендә генә, биш көн йөреп, Оренбург төбәгеннән кайтып җиткән идек, якшәмбедә, инде төн кергәндә, Мурманск өлкәсенә чыгып китәргә туры килде. «Юл газабы – гүр газабы», дисәләр дә, япа-ялгыз көе Мурманск, Североморск кебек ябык, «яшерен» калаларга барып эләгү мөмкин гамәл түгел, ыңгырчак-дилбегәләр киеп, тагын сәфәр чыктык.

●Североморск каласын төзү Ваенга борынындагы менә шушы тәүге йортлардан башланган.

●В.Шәйхразыев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе һәм Мурманск өлкәсенең губернатор урынбасары В.Евменьков очрашуы.

Мурманск Төньяк боз океанының бер өлеше булган Баренц диңгезенә терәлеп, аның коры җиргә кергән бухтасын тирәләп урнашкан. Аэропорт Кола дип аталган бистәдә урнашкан, анысы 4-5 гасыр элек үк нигезләнгән икән. Ә Коладан 45 чакрымдагы Мурманск каласына 1915 елда гына нигез сала башлаганнар. Шуннан бер ел элек Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Германия, Франция, Англия кебек дошман илләр Кара диңгезне дә, Балтыйк диңгезен дә үз тырнакларына эләктереп, Россиянең ул тарафтагы барча портларын бикләп куйган. Дустанәрәк булып кыланган илләр белән сәүдә итү, анысыннан да бигрәк корал алышу өчен, патша хөкүмәтенә ашыгыч рәвештә шушы Баренц диңгезендә яңа порт ачарга туры килгән. Океандагы су тәүлек яки атна дәвамында йә килеп, йә китеп торганга күрә, Баренц диңгезе беркайчан да катмый, ул ел әйләнәсендә товар озата йә чит ил корабларын кабул итә ала. Патша хөкүмәте бик нык ашыкса да, Мурманск портын тиешенчә төзеп бетерергә барыбер җитешми, ул Россиядә патша заманында сафка бастырылган иң соңгы шәһәр булып, тарихка кереп кала. Ә ул арада Швейцария кунакханәләрендә качып яткан большевик әйдәманнары Германия аша ябык вагоннарда кайтып җитә дә, Петербург каласында Германия акчасына террористик түнтәреш ясап ташлый. Гражданнар сугышы вакытында шушы Мурманск һәм Архангельск портлары аша Россиягә Америка һәм Англия гаскәре бәреп керә. Инде илне барча дошманнардан чистарткач кына, яңа совет хөкүмәте Мурманскины да искә төшерә. Яр буендагы таш кыялар өстен беркадәр кирпеч, ә күбесенчә агач йортлар сырып ала. Бөек Ватан сугышы чорында Мурманск лендлиз программасы буенча Америка һәм Англиядән килгән техника һәм азык-төлекне кабул итеп торган төп портка әверелә. Гитлер Мурманск каласының стратегик әһәмиятен белеп торса да, тәүге елларда әле аңа тими, аны үз кулына эләктереп, Германия файдасына куллану турында хыяллана. Ә инде сугышта оттырачагын аңлап алуга ук, Мурманск каласы өстенә дистәләрчә эскадрилья самолетлар юллый һәм шәһәрне атналар буе бомбалар яудырып җимертә. Сугыш башланган вакытта әле ярый Төньяк флот белән генерал-майор Александр Кузнецов җитәкчелек итә. Сталин 21 июнь төнендә көнбатыш чикләрдәге барча совет гаскәрләрен сугышчан хәлгә китерү турында фәрман биргән булса, генерал Кузнецов, үз җаваплылыгына алып, инде өч тәүлек элек үк сугышка хәзерлек чараларын күрә башлый. Нәкъ шушы генерал фәрманы буенча Баренц диңгезенә керә торган бугазларда кыялар өстенә диңгез туплары урнаштырыла, ул хәтта төрмәләрдә тотылучы җинаятьчеләрне дә чыгарып һәм аларны солдат һәм матрослар белән аралаштырып, портлар сагына бастыра. Алдан күрүчәнлек нәтиҗәсендә немец гаскәрләре Баренц ярларына да, портларга да үтеп керә алмый, Мурманск барлык сугыш айлары буена совет иленә ярдәм итеп тора...

Сугыш дәһшәтләре көнбатышка таба үтеп киткәч, Мурманск каласын тиз арада сафка бастыралар. Йортларның яртысы таш һәм кирпечтән төзелсә, яртысын Себер тайгаларында үскән нарат һәм карагай брусларыннан күтәрәләр. Йортларның биеклеге ике каттан артмый. 1960 елларда гына Мурманскига да заманында «хрущевка» дип аталган, панельләрдән биш катлы йортлар калкыту технологиясе килеп җитә. Хәзер инде калада Казан яки Мәскәүдәге шикелле заманча, күпкатлы йортлардан хасил яңа микрорайоннар да үсеп чыккан. Заманча кунакханәләр, кафе һәм рестораннар, сәүдә үзәкләре дә җитәрлек. Яманы шул – нәкъ Казанда яки Ижаудагы шикелле үк, кәттә ресторан, кунакханә һәм сәүдә үзәкләренә исемнәре җиде йозак артына яшерелгән Мәскәү олигархлары һәм караклар хуҗа. Баренц диңгезе ярларында һәм Кола ярымутравында бер генә авыл да юк, тик таш кала һәм бистәләр генә тезелгән. Мондагы тоташ кыялардан йә күл вә сазлыклардан хасил җирлектә ашлык үстерү яки мал асрау гомумән мөмкин түгел. Сәнәгать объектларыннан җылылык, су, газ һәм электр челтәрләре, коммуналь хезмәт күрсәтү, автотранспорт предприятиеләре, балык эшкәртү заводлары һәм портларда кораб ремонтлау верфьләре генә бар. Поляр түгәрәк артында хезмәт хакына төньяк өстәмәләр каралса да, эш урыны юклыктан, халык саны ел саен кимүгә таба бара. Узган ел гына да өлкәдә яшәүчеләрнең 17 процентка якыны Россиянең башка төбәкләренә һәм чит илләргә күчеп киткән, бүген мондагы халык саны 667 меңнән артмый, Мурманск каласының үзендә 232 мең чамасы гына кеше яши...

Биредә яшәү шартлары да бик җиңелдән түгел. Без барган октябрь ае ахырында поляр төннәр әле башланмаган, әмма барыбер күк йөзе фәкать сәгать уннар тирәсендә генә генә яктыра, ә көндезге 15 сәгать җитүгә үк шәһәр урамнарын янә эңгер-меңгер баса. Аңлашыла булыр, заманча шәп йортлардагы кәттә фатирларга кара гавамның егәре бик җитми, шул сәбәптәндер, меңнәрчә кеше илленче еллар тирәсендә төзелгән ике катлы, шифер түбәле, бернинди уңайлыклары да булмаган иске йортларда, бер өлеше хәтта агач баракларда яши. Дөрес, кешеләр уңайлырак төбәкләргә күчеп киткәннән соң, ул ике катлы иске йортларның күбесе бушап ук калган инде...

Мурманск каласында безне губернатор урынбасары В.Евменьков кабул итте, аннан соң, бергәләп, диңгез ярында урнашкан

●Халыклар дуслыгы йортында татар адмиралы, Казан егете Илдар Әхмәров чыгыш ясый.

● Ә без – актанышлылар.

ТӨНЬЯК БАШКАЛАСЫ

●Мурманск каласы күренеше. Сул якта биек сопка өстенә куелган Алеша һәйкәле төсмерләнә.

атом бозваткычларын ремонтлау заводына киттек. Илленче елларда бу урында механик-ремонт остаханәсе генә булган, менә шунда эшли башлаган Әстерхан татары Әнвәр Ибраһим улы Тумбаров аны илкүләм дан алган «Росатоммаш» заводына әйләндергән, предприятиене 28 ел дәвамында үзе җитәкләгән. Ул хәзер бик яшерен оешма, анда 9-10 катлы йортлар биеклегендәге бозваткычлар ремонтлана. Предприятенең диварына Ә.Тумбаров исеме язылган истәлек тактасын беркетүгә үк, безне «Җиңүнең 50 еллыгы» дип аталган гаҗәеп зур кораб эченә экскурсиягә дә алып керделәр. Бөтен ваклыкларын санау ярап бетми, иллә мәгәр бозваткыч эчендәге баскычлар буйлап бишәр-алтышар катка йөгереп төшә-менә, шактый тиргә баттык. Мондый кораб Төньяк боз океанын ерып йөргән чакта тәүлегенә унөч миллион сум бәясенә төшә. Чыгымнарның бер өлешен кире кайтару өчен пассажирлар да алалар һәм аларны Франс-Иосиф утравы тирәли сәяхәт иттереп тә кайтаралар икән. Андый 11-12 тәүлеклек сәяхәт сыңар пассажирга утыз мең долларга төшә, сөяркәсе белән юлга чыкса, икесенә 20 млн сум тирәсе агач акча чыгарып салу тиеш. Аңлыйсыздыр: мондый сәяхәтләр безнең кебек кара халыкларның төшенә дә керми...

●Россиянең диңгез флагы янында истәлеккә фото.

Мурманск үзәгендәге бер биек сопка түбәсенә куелган Алёша һәйкәле янына баргач, тәмам хәйран калдык. Һәйкәлнең биеклеге 45 метр! Ул каланың һәр почмагыннан күренә. Аны бастыру өчен бернинди Мәскәү әһеленнән дә рөхсәт сорап тормаганнар. Ә без, утыз ел буе хөкүмәткә туктаусыз ялынып та, газиз башкалабыз уртасына безгә дәүләт – Казан ханлыгын төзеп биргән Олуг Мөхәммәт ханга һәйкәл куя алмыйбыз соң?!

Сәфәребезнең икенче көне өлкә мәркәзеннән 30 чакрымдагы Североморск каласында дәвам итте.

Анда әүвәл Төньяк флот командующие адмирал, Россия Герое А.Моисеев белән очраштык, аннары Ваенга борынындагы причалда агымдагы ремонтка тукталган «Маршал Дмитрий Устинов» исемендәге ракета крейсерында кунакта булдык. Аның «күзләре» дошманны 550 чакрым ераклыктан күреп өлгерә һәм теләсә кайсы объектны 74 чакрым арадан юк итә ала икән. Крейсерның үзенә герб итеп алган билгесе дә кобра еланы – шул үзе үк аның никадәр куркыныч көчкә ия булуын мисалларсыз да аңлатып бирә сыман.

Без алдагы кичтә Мурманскиның Ленин округында урнашкан Халыклар дуслыгы йортында бу төбәктә яшәүче татар кешеләре белән очрашу оештырган идек, ә икенче көнне Сафоново бистәсендә Төньяк флот авиациясенең музей бинасында Татарстаннан китеп шушы флотта хезмәт итүче офицерлар, мичманнар һәм матрослар белән очрашу көтеп торган.

(Дәвамы 14 нче биттә).

●Без сәяхәт кылган «Маршал Устинов» крейсеры.

●Мурманск портындагы причаллар.

Мәдәни җомга
3 ноябрь
№43, 2022

●Сафоново музеенда хәрби якташлар белән бергә төшкән фото.

Мурманск – төньяк башкаласы

(Ахыры. Башы 12 нче биттә).

Ни гаҗәп, хәрби хезмәттәге якташлар белән күрешү искиткеч дәрәҗәдә кайнар һәм эчкерсез булып чыкты. «Кайсы районнан?» – дип сорау ташлауга ук, Азнакай, Саба, Норлат, Актаныш, Чаллы, Әлмәт, Яшел Үзән... егетләре «чәчрәп» торды. Мин фәкыйрегез туган Актаныш районының Аеш һәм Әлем авылларыннан монда ике якташ хезмәт итә икән. «Сезне күргәч, әти-әни белән очрашкандай булдык», – дип бер дә тарсынмыйча кочаклап та алдылар. Әлем егете без әле генә күргән «Маршал Устинов» крейсерында 16 ел хезмәт итә, читтән торып бер институтны тәмамлап килә, якын арада офицер дәрәҗәсен алу турында да хыяллана. Аеш егете әле күптән түгел генә хезмәткә килгән, ләкин иген кырларын сагынудан һич туктый алмый. Берүк аларның һәркайсына исән-имин көе туган якларына әйләнеп кайту язсын...

Мурманск өлкәсендә 6 меңгә якын татар гомер итә. Яртысы диярлек туган телен оныта башласа да, Халыклар дуслыгы йортындагы очрашу вакытында Татарстанның премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев «Күбәләгем», «Ай, былбылым» кебек җырларны суза башлауга ук, барысы тиң аңа кушылды. Туган тел, әлбәттә, якын да, кадерле дә. «Маршал Устинов» крейсерының диварына адмирал Павел Нахимов 1850 елларда ук әйткән: «Үзең сөйләшә торган телнең, үзең яшәгән каютаның, үзең кигән мундирның кадерен бел!» – дигән сүзләрне тиктомалдан гына иң күренекле урынга элеп куймаганнар. Тел һәм милләт безгә бик кадерле. Кирза итекләр киеп, татар мәктәпләренә басып кергән чакта моны Мәскәү әһелләре дә искә тотсын иде.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

●Сафоново музеенда Төньяк флот авиациясендә хезмәт иткән җиреннән космонавтлар отрядына алынган Ю.Гагаринның музей-йорты.

●Сафоново бистәсе музеенда 1942 елда һәлак булса да ике мәртәбә Советлар Союзы Герое исемен яуларга өлгергән Борис Сафонов һәм аның Герой полкташлары хөрмәтенә куелган бюстлар.

●Североморск каласы үзәгендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган матрослар истәлегенә куелган һәйкәл.

●Мурманск үзәгендәге сопкага куелган, биеклеге 45 метрга җиткән Алеша һәйкәле.

Әнәк авылы

(Дәвамы. Башы 42 нче санда).

Торынтаешның 1762 елгы ревизия документы бу мәгълүматларны шактый тулыландыра, шулай ук күчеп утыручыларның күбрәк булуын күрсәтә. Документ төгәл итеп старшина Минәй Бикбов командасыннан – 46, старшина Уразмәт Йосыпов командасыннан – 17, старшина Сөендек Тукбаев командасыннан – 8, старшина Нияз Ибраев командасыннан – 7, старшина Ураз Десятов командасыннан 5 ир-ат күчеп утыруын раслый. Документта Сарашлы елгасы буендагы Әнәктән (чыганакта «Аняково, что на речке Сарашле») 17 ир-ат (шул исәптән Туймәс Килмәкәев, Шәрип һәм Рахманкол Илкиннар, Мәсәй Морзин, Ибрай Ишкенин, Габделкәрим Әлмәкәев, Гомәр Байгилдин) күрсәтелә (РБАДА, 350 ф., 2 тасв., Д. 3801 сакл. бер., 1187-1193 б.). Әлеге Мәсәй Морзин – Торынтаеш авылы исемлегендә аерым һәм вафат булган дип теркәлгән, кайсы авылга караганы күрсәтелмәгән Морза Әнәковның улы булырга тиеш.

Уфа провинциаль канцеляриясенең 1760 елның 14 мартына караган указында әлеге ясаклы татарларга мөрәҗәгатьтән: *«Сего марта 10-го дня доношением, поданным в реченную правинцыальную канцелярию, объявляя, что жительством вы состоите в предъявленных деревнях, в коих и по минувшей генеральной ревизии написаны, токмо в домашнем по вашему обыкновению извороте, яко то в хлебопашестве, коего по посеву вашему ничего не родится, а особливо и земли в окружность тех деревень предписано и сенных лугов имеется самое малое число, да и в лесу едва ко исправлению домашних економией находить [не] можете к снятию лубьев способных дерев, и ничего в тех окружностях приписанным к деревням вашим найти не можете, которые де вы принуждены были по потребности до сего издалека привозить, и так в том имеете крайней недостаток, что домашнею екаsucces номиею чрез несколько лет поправить, как то протчия ваша братья обзавелись, и не можете. Отчего убегая, как бы не приттить в невсостояние и не отстать бы и платежем подлежащего в казну ясака, взяли по уступке Уфимского уезду, Нагайской дороги, Яиксуби-Минской волости сотника Идриса Муашева, правящего старшинскую должность Якшимбетя Бекташева, бывшаго сотника ж Аккулая Бекташева с товарыщи вотчинную способную к житью и к домашнему по вашему обыкновению извороту землю по межам, явствующим в данном вам от них татарском письме, с коего впредь обязались они вам дать от крепостных дел запись, из оброку платежем на год с каждого двора по 15-ти коп. и общей с ними подводной гоньбы, понеже де мимо то[го] жительство, где оная нынешняя помянутым сотником Идрисем с товарыщи уступленная вам земля имеется, проложена к городу Оренбургу Ново-Московская дорога, где вы по достатку земли и протчего, яко то лесов, сенных лугов, поселиться и жительствовать, не исключая и команд, в коих вы ныне находитесь, усердно желаете, токмо без указу здешней канцелярии для житья опасны. Просили, чтоб вам в предписанную Яиксуби-Минскую волость на кортомленную вами у помянутых сотника Идриса, с товарыщи землю для житья переехать дозволить…»* (МИБ. Т. 4. Ч. 2. – С. 28. Документ № 362).

Әлеге тексттан күренгәнчә, Казан юлының төрле җир олысларына караган ясаклы татарларның Ногай юлына күчеп утыруларының төп сәбәбе – аларның үз авылларында эшкәртергә җирләре һәм урман-болыннары аз булу. Яңа урында алар биләмәчеләргә һәр хуҗалыктан (йорттан) ел саен 15 сум түләп барырга һәм алар белән берргәттән дәүләткә тиешле бурычларны үтәргә тиеш була.

Уфа провинциаль канцеляриясенең 1760 елның 16 мартындагы указында Яиксуба-Мин олысы биләмәләренә күченүчеләр ясаклы татарлар дип күрсәтелә. Димәк, Әнәк авылы халкы 1760 елда да ясаклы татар сословиесендә була. Бары 1762 елгы ревизия документында гына алар беренче тапкыр типтәр сословиесендә теркәлә.

1762 ЕЛГЫ ИСЕМЛЕКТӘ – АВЫЛ НӘСЕЛЛӘРЕ

1762 елда Әнәктә 44 ир-ат теркәлә. Авыл халкы старшина Минәй Бикбов командасында исәпләнгән. Әнәк белән берргәттән, аның командасында 36 авыл (Әтрәкле, Мөшегә, Мари Бүләр һ. б.) «типтәр»ләре күрсәтелә.



● Әнәк авылы буенча 1762 елгы исемлекнең беренче бите. Беренчеләр булып Морза нәселен дәвам итүчеләр теркәлгән.

Исемлек башында Мәүлекәй Морзин (55 яшь), аның уллары Фәтхулла (8), Мөрсәлим (вафат), Шәрип Морзин (45), аның уллары Габдерәхим (12), Абдулла (8), Гобәйдулла (1 – чыганакта «Гипалла»), Исергәп Морзаев (вафат), аның уллары Сөендек (35), Сагындык (31); аның улы Рәхмәтулла (1) теркәлгән.

Әлеге мәгълүматлар нәсел башында Морза исемле кеше торуын, нәселнең зур булуын күрсәтә. Шуңа шартлы рәвештә Морза нәселе дип атарга була. Бүгенге көндә бу нәселдән Шәех Фәрдиевнең балалары һәм оныклары билгеле.

Икенче зур нәселгә Ишкилде Юлаев (40 яшь), аның уллары Миңлегол (6), Ишмөхәммәт (10), Кушкилде Юлаев (37), аның уллары Әбубакир (7), Бәшир (4), Хәмит (1), Сөләйман Юлаев (35), аның улы Габдерәхим (2) һәм туганы Габдессәлам [Юлаев] (30) керә. Нәсел башында Юлай исемле кеше торуын искә алып, Юлай нәселе дип атый алабыз. Алдагы бүлектә Юлайның фамилиясе Мәкәев булуын күрсәтеп үткән идек.

Өченче зур нәселне Ибрай Килмәкәев (75 яшь), аның уллары Ямангол (20), Миңлегол (18), Сөбханкол (10), Миңлебай (8), Имангол (3) тәшкил итә. Башында Килмөхәммәт һәм аның улы Ибраһим торган бу нәселне барлык Татарстанга танылган



● Исемлектә Ибрай Килмәкәев һәм аның 5 улы теркәлгән.

шәхес – җөмһүриятебезнең Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев.

Дүртенче нәсел итеп Ает Илмәтов (70 яшь), аның уллары Габдрахман (20) һәм Габделҗәлил (7) атала ала. Бу нәселне Илмәт (Илмөхәммәт) нәселе дип атарга була. Илмөхәммәт алдарак күрсәтелгән Килмөхәммәт белән бертуган булырга мөмкин, моны нәсел тамгаларын өйрәнеп тәгаен ачыкларга була.

Бишенче нәсел итеп Мәсгут Мәмәтколов (вафат), аның уллары Дәмин (30), Ишем (10) күрсәтелә ала. Соңгысының тулы исеме «Ишембай» булып, чыганакта аның кыскартылган (диалекталь) варианты язылган дип уйларга кирәк. Нәсел башында Мәмәткол исемле кеше торуын искә алып, Мәмәткол нәселе дип атый алабыз.

Исәй Әнәков (вафат), аның улы Мортаза (35 яшь), Мансур Морзин (вафат), аның улы Искәндәр (4), Мөэмин Йөзәев (30), аның улы Кинҗә (1) аерым нәселләр булып карала ала кебек (нәсел тамгаларын өйрәнү тулы ачыклык кертә алыр иде).

Әнәк авылы исемлегендә варислары булмаган ир-атлар да күзгә ташлана. Болар – Балтач Миңлебаев (50яшь), Апас Сарбашев (80; аның туганы Сарман вафат булган), Ишем Ишмәтов (60).

Йөзәй Әнәков һәм аның улы Ишкенә вафат булганнар, варислары калмаган. Алдарак телгә алган Исәй Әнәковне күз алдында тотып, авылга нигез салучы Әнәкнең 2 улы булган, шуларның берсеннән нәсел дәвам иткән дигән нәтиҗәгә киләбез.

Шулай итеп, 1762 елгы исемлек зур әһәмияткә ия. Авыл күптәннән яшәп килсә дә, аның нәселләре беренче тапкыр шушы чыганакта телгә алына. Бу чыганак Әнәкнең улларын теркәп, авылга нигез салучы шул булган дип дәлилле фараз кылырга мөмкинчелек бирә.

Торынтаешка күчеп утырган Сарашлы елгасы буендагы Әнәк авылы кешеләре түбәндәгеләр: Туймәч Килмәкәев (37 яшь), Шәрипкол Илкин (57; аның уллары Әмин, Зәбир, Йосып), Рахманкол Илкин (вафат; аның улы Рәмкол), Мәсәй Морзин (50; уллары Мәдияр, Габдерәшит, Габделваһап, Габделмәннан), Ибрай Ишкенин (45; уллары Сәйфелмөлек, Сәйфулла, Нигъмәтулла, Яһудә), Габделкәрим Әлмәкәев (16; улы Тимер), Гомәр Байгилдин (32) (РБАДА, 350 ф., 2 тасв., 3801 сакл.бер., 1190 б.). Болардан Габделкәрим Әлмәкәев соңыннан Әнәкнең 1795 елгы ревизия документында теркәлә.

Торынтаеш авылына күчеп утыручылар старшина Мәксүт Морзакаев командасына керә. Югарыда күрсәтелгән Әнәк ир-атларыннан тыш, әлеге команда составында түбәндәге авылларның ир-атлары теркәлә: Торынтаеш («Турунтаишева, что на речке Нурме»; 59 ир-ат), Шәйчура («Шайчюрино, что на речке Базене»; 5 ир-ат), Тузганабикә («Тюзгиной Бика, что на речке Ик»; 10 ир-ат), Бүләр («Булярово, что на речке Иски Буляр»; 7 ир-ат), Шах («Шаково, что на речке Кудаше»; 6 ир-ат), Васильево («Васильево, что на речке Менетмень»; 2 ир-ат), Никифар («Никифорово, что на речке Узянли»; 5 ир-ат), Җәмәк («Ямаково, что на речке Узянли»; 5 ир-ат), барысы 119 ир-ат (Шунда ук, 1187-1193 б.). Васильево авылы соңрак Иске Васильевкага әйләнә. Җәмәк авылы Гайниҗәмәк дип тә йөртелә.

Гайниҗәмәк, Торынтаеш, Иске Васильевка, Никифар – бүгенге көндә Башкортстанның Әлшәй районына керүче авыллар. Шах авылы исә Ярмәкәй районына карый.

Әнәк, Шәйчура, Тузганабикә, Бүләр авылларыннан күчеп киткән типтәр сословиесендәге татарлар Торынтаешта төпләнә. Моны ачыклау өчен без Торынтаешның 1795 елгы ревизия документын өйрәндек, анда элек Әнәк, Шәйчура, Тузганабикә, Бүләр авылларында яшәгән ир-атларны таптык.

Чыгышы буенча Әнәк авылыннан булган Мәдияр (51), Габдерәшит (44), Габделваһап (39), Габделмәннан (34), Габделҗәлил (30) Мәсәевлар, Әмин (52), Зәбир (44), Йосып (39) Шәрипколовлар 1795 елда Торынтаешта зур нәселләрдән санала. Йосып Шәрипколов Уфа наместничествосы идарәсе указы нигезендә авылның мулласы, мөхтәсиб һәм мөдәррисе итеп билгеләнә. Аның хатыны Бөгелмә округы Нәдер авылыннан була (БР МА, И-138 ф., 2 тасв., 34 сакл. бер., 423 б. а.-435 б. а.).

Старшина Мәксүт Морзакаев та (1795 елда 67 яшь) Торынтаешта яши. Шунысы игътибарга лаек, аның беренче хатыны Минзәлә округы Чуракай авылы «башкорт»ы кызы Салиха Чуракаева (63 яшь) була. Димәк, ул хәзерге Актаныш районының Чуракай авылына нигез салган Чуракай исемле биләмәче гаиләсендә якынча 1733 елда туган (Шунда ук, 413 б.).

Шулай итеп, Торынтаешка Әнәк авылыннан 55 ир-атның 19 ы күчеп утырган. Әнәктә калган типтәр сословиесендәге 36 ир-ат исәбендә Татарстанның беренче Президенты М.Шәймиевнең бабасы Ибрай Килмәкәев һәм аның уллары була.

ӘНӘК 1795 ЕЛДА. НӘСЕЛЛӘР КИРЕ КАЙТА

1773-1775 елгы Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышында катнашкан авыллар исемлегендә Әнәк тә телгә алына. Документта аның халкы старшиналар Өметкол Тәүкилев һәм Мәксүт Морзакаевлар командасына кергән ясаклы татарлар дип язылган (Крестьянская война 1773-1775 гг. на территории Башкирии. Сборник документов. – Уфа, 1975.– с. 281-282). Әлеге факт татарларны «типтәр» дип язу тулы көченә кермәгәнлеген күрсәтә.

1781 елның 23 декабрендә патшабикә Екатерина II Уфа наместничествосын булдыру турында указга кул куя. Ул Оренбург (составына Бозаулык, Югары Урал, Оренбург һәм Сергиевск өязләре керә) һәм Уфа (составында Бәләбәй, Бөре, Бөгелмә, Богырыслан, Минзәлә, Стәрлетамак, Уфа, Чиләбе өязләре) өлкәләрен үз эченә ала. Әмма «Әби патша»ны яратмаган император Павел I, хакимияткә килү белән, аның күп реформаларын юкка чыгара. Яңа указ нигезендә Уфа наместничествосы 1796 елның 12 декабреннән Оренбург губернасына әйләнә, өлкәләр бетерелә, ә өязләр үзгәрешсез кала.

1782 елда Әнәктә нибары 40 ир-ат һәм 23 хатын-кыз теркәлә. 1762 ел белән чагыштырганда, ир-атлар саны азаюның сәбәбе нәрсәдә?

(Дәвамы киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ.

Атнаның сәяси мизгелләре

УҢЫШСЫЗ ТАКТИКА

Узган шимбәдә Украина хәрбиләренең, очучысыз очкычлар (ОО) һәм диңгез автоном аппаратлары (ДАА) кулланып, Россия Кара диңгез флотының (КДФ) Севастопольдә бухтада торган хәрби корабларына һөҗүм итүе сәяси һәм хәрби даирәләрдә зур ыгы-зыгы китереп чыгарды. Россия саклану министрлыгы хәбәренә караганда, берничә сәгать дәвам иткән ул һөҗүмдә 9 ОО һәм 7 ДАА катнашкан һәм алар барысы да КДФ тарафыннан юк ителгән. Тәүге хәбәрдә бердәнбер зыянның янәшәдәге тулай торакта тәрәзә пыяласы чатнавы булуы әйтелсә дә, соңрак «Иван Голубец» тральщигына һәм бухтадагы челтәрле йөзмә киртәгә дә бераз зыян салынуын әйттеләр. Мәскәү исә әлеге һөҗүмне «ашлык коридоры»н саклауга җәлеп ителгән хәрби корабларга Киев режимының Бөекбритания белгечләре дә катнашында кылынган террор акты буларак бәяләде. Украина хәрбиләре аны оештырганда «гуманитар коридор»ны кулланган дип, Россия үзенең «ашлык килешүе»ндә катнашуын билгесез вакытка туктатып торырга карар кылды һәм моның өчен җаваплылыкны Киев белән Лондонга йөкләде, бу хакта рәсми төстә БМО генераль секретаренә дә хәбәр итте. БМО исә суднолар йөрешен Киев һәм Анкара белән килешенеп кенә хәл итәргә булды. Вашингтон да Мәскәүнең гаепләүләрен чынга алмады һәм аның әлеге адымын дөньякүләм азык-төлек проблемасын кискенләштерү ниятендә кылынган инсинуация буларак бәяләде.

Ә Севастопольдә хәрби корабларга салынган зыянның зурлыгы инде икенче һәм аннан соңгы көннәрдә Украинаның инфраструктура объектларына ясалган ракета һөҗүмнәрендә күренде. Бу, күрәсең, Киевне сөйләшүләргә мәҗбүр итү ниятендә эшләнә. Чөнки «арадашчылар» (әйтик, Э.Макрон, А.Меркель, Р.Эрдоган, Рим Папасы һ.б.) аша мөрәҗәгать итүләр нәтиҗә бирмәде. Бу эшкә хәтта Гвинея-Бисау президентын да җәлеп итеп карадылар кебек, тик файдасыз. Ә игътибарны тактик максатлы атомтөш коралы турындагы имеш-мимешләр дә, газ кризисы белән куркыту яки «пычрак бомба» турындагы янаулар да, башка хәбәрләр дә җәлеп итә. Соңгыларын инде сөйләшүләрне башлап җибәрергә Көнбатышны да этәрү чаралары дип карарга кирәктер. Украина буенча сөйләшүләрне әүвәл Вашингтоннан башлау кирәклеге турында узган атнада Д.Песков та, С.Лавров та, хәтта Президент В.Путин үзе дә белдерде.

Башка вакыйгалардан игътибарны Россиядә өлешчә мобилизация буенча чакыруның төгәлләнүе, Херсон өлкәсендә Украина гаскәрләренең колачлы һөҗүмгә әзерләнүе турында хәбәр пәйда булуы, Россия гаскәрләренең Украинадагы «Үзәк» төркеме командующие генерал-полковник А.Лапинның вазыйфасыннан алынуы, Россия хөкүмәтенең дус булмаган илләр исемлеген киңәйтүе һ.б. җәлеп итә. Мәгәр, Украинадагы махсус хәрби операциянең Россия мәктәпләрендә өлкән сыйныфлар өчен тарих курсына кертелүе дә күп нәрсә турында сөйли.

Фоат УРАЗАЙ.

Җәүһәргә тиң

Гәүһәр Камалованың 100 еллыгына

Бөек драматургыбыз Галиәсгар Камал: «...Мин театрга әсәрләрем белән генә түгел, уеным, киемнәрем белән дә күп кенә ярдәм иттем», – ди үзенең «Яза башлавымның тарихы» дип исемләнгән хатирәләрендә. Әйе, «Сәйяр» труппасы яши башлаган дәвердә Г.Камал катнашмаган, артистларга терәк булмаган бер вакыйга да булмагандыр, мөгаен. Театрда экскурсияләр үткәргәндә мин: «Драматург әле үзенең нәселе, якыннары белән дә татар театрының үсешенә булышкан, аны баеткан», – дип өстим. Әйе, Галиәсгарның театрга булган мәхәббәте барлык туганнарына, балаларына да күчә, аларның театр юлын сайлавына сәбәпче һәм этәргеч була. Шулай итеп, татар театрында Камаллар династиясе барлыкка килә. Энеләре Габдулла Камал I, Габдрахман Камал II, сеңлесе Зәйнәп Камалова, улы Әнәс һәм Фаикъ, Камал I хатыны Фатыйма, кызы Гәүһәр дә бөтен гомерләрен милли театр сәнгатенә багышлаганнар (Фаикъның гына гомерен бик яшьли сугыш өзә). Менә шуларны күздән кичерсәң, академия театрыбызның Г.Камал исемендә булуы бик табигый һәм хаклы икәненә янә инанасың. Әтиләре Галиәкбәр абзыйның: «Үзем укый алмадым, инде балаларым йә дин юлында, йә сәүдә дөньясында зур кеше булырлар», – дип аларга белем бирүе атаның өметләрен акламаса да, уллары татар халкы горурланырлык зур кешеләргә әйләнә! Үзе исән чагында бәяләп бетерә алгандырмы ул моны яисә иске фикерендә калгандырмы... Һәрхәлдә рухы шат булсын, рәхмәт аңа!

Ә без, хөрмәтле укучым, Камал театрындагы Камаллар династиясенең әлегә соңгы чылбыры булган Гәүһәр Камалованы искә алыйк. Аның тууына 100 ел тулды. Әнисе Фатыйма Камалова кебек үк мактаулы исемнәргә лаек булган, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Гәүһәр ханым театраль гаиләдә тууы белән үк инде сәнгать, сәхнә дөньясына дучар ителә. «Сәйяр» труппасы артисты, режиссеры Габдулла Камал 1917 елгы революциядән соң, күп кенә артистларыбыз кебек, Урта Азия якларына милли театр учаклары кабызырга җибәрелә һәм Гәүһәрнең туган җире Ташкент була. Ул инде 4 яшьтә сәхнәдә Г.Тукайның «Бала белән Күбәләг»ен сөйләп «дан» казана. Берничә елдан соң Оренбургтагы бер спектакльдә малай ролен гаҗәп табигый уйнап чыккан кызга театр белгече Галимҗан Нигъмәти дә шакката. Казанга кайтып, татар радиосының беренче режиссерларыннан булган Камал I нең гомере Галиәсгар абыйсы белән бер үк елда (1933), бер үк айда өзелә. Драматург һич көтмәгәндә, әнекәше Габдулла шактый озак авырып, нибары 40 яшендә бакыйлыкка күчә. Бу чакта кызы Гәүһәргә 11 яшь кенә тулып килә. Сабый тормышында беренче зур югалту... Әмма әтисе инде аңа юл күрсәтеп китә. Сугыш башлангач, Гәүһәр хәрби заводта, аннан башка урыннарда эшли. Ә 1944 елда Мәскәүдәге театр сәнгать институтында (ГИТИС) татар театры өчен махсус ачылган студиягә укырга керә. Булачак сәхнә йолдызларын башкаланың дан казанган сәнгатькәрләре, күренекле педагоглар Пыжова, Тарханов, Поповлар укыта. Бу студиядә чынлап та «йолдызлар»



● Ф.Камалова кызы Гәүһәр белән.

белем ала: (Камаллар гаиләсеннән Гәүһәр, Нәкый Исәнбәт улы Празат, артистка Гөлсем Камская һәм режиссер Гали Ильясов улы Деллюс, Габдулла Уральский кызы Роза, Мөкәррәмә Әсфәндиярова кызы Шәхсәнәм.) Театр дөньясындагы күренекле шәхесләр – Рәфкать Бикчәнтәев, Асия Гали, Асия Хәйруллина, Асия Харисова, Рауза Әхмәрова, Гали Хөсәенов та – Гәүһәрнең сабакташлары.

Акыллы, талантлы Гәүһәр үзенең кемнәр нәселеннән булуын бик яхшы аңлый. Әнисе дә, аны озатканда, Камаллар исеменә тап төшермәскә, тырыш булырга кушып, үгет-нәсыйхәт бирә. Әле сугыш барган авыр көннәрдә аларны башкалага укырга җибәргән Татарстан хөкүмәте алдындагы җаваплылыкны да тоя ул. Һәм бик яратып, теләп укый. Дәүләтнең югары стипендиясен ала, курста староста була. Диплом спектаклендә Камалова иҗат иткән Васса Железнова образы тәҗрибәле артистлар дәрәҗәсендәге камиллеге, төгәллеге, тирәнлеге белән институт тарихына да, соңрак театр тарихына да кереп кала. Остазлары М.Горькийның бу күренекле әсәрен курста нәкъ Г.Камалова булганга алалар да. 1949 елда студияне тәмамлаган яшьләр Казандагы яшь тамашачылар театрында эшли башлый, 1 ел дәвамында татарча спектакльләр күрсәтәләр. 1950 елдан Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына кушылалар һәм күренекле өлкән буын артистларын лаеклы алыштырырлык сәхнә осталарына әйләнәләр.

Гәүһәр Камалова яшь чакта төз гәүдәле, сылу, бик сөйкемле йөзле, нурлы күзле һәм күкрәктән чыккан көчле тавыш иясе. Сәхнәдә бик тормышчан булып яши белүе, килешле төс-кыяфәте белән ул тамашачыларны бер күрүдә яраттыра. Көчле кичерешләрне чагылдыра алган драматик таланты һәм юморга да бай булуы аңа киң диапазон белән төрле жанрда онытылмаслык, кабатланмас образлар тудырырга ярдәм итә. Соңгы елларда гәүдәгә

● «Банкрот». Нәгыймә.

● «Монда тудык, монда үстек». Рауза.

Гәүһәр

● Г.Камалова энисе Ф.Камалова белән.

тулыланып киткән Гәүһәр ханым сәхнәдә һаман да җиңел атлый, хәер, ул бернинди хәрәкәтләр ясамыйча да, роленең уй-фикерен, халәтен оста күрсәтә. Образының бөтен биографиясе, холык-фигыле бай төсмерле калын, көр тавышыннан, гаҗәеп эчтәлекле, прожекторга тиңләрлек күз карашыннан бик ачык аңлашыла иде. Зур сәхнәләрне берүзе сүзсез дә тутырып тора алу көче, мәгърур сәхнә темпераменты бар иде анда.

Ч.Айтматовның «Анам кыры» әсәре буенча куелган телевизион спектакль 60 нчы еллар ахырында бөтен татар тамашачыларын кузгатты, тетрәтте, хәтта русларны да битараф калдырмады. Театр архивында сакланган хатлар шул хакта сөйли. Аларда – Тулганай Ана образындагы Гәүһәр Камалованың уенына сокланып, чын күңелдән әйтелгән эчкерсез рәхмәт сүзләре. Сугышта бөркеттәй өч улын, яраткан ирен югалткан Тулганай – Гәүһәр бөтен Аналарның хәсрәтен берүзенә туплагандай тирән кичерешләр белән яши... Моннан соң Г.Камалова турында: «Ул шундый фаҗигале образлар өчен генә яратылган талантлы артистка», – дип уйлар идең, әгәр.. Әгәр аны Х.Вахитның «Күк капусы ачылса» водевилендә Шәмсия ролендә күрмәсәң! Камаллар нәселенең бу данлы артисткасын сәхнәдә күреп калуыма, тормышта да аралашуыма мин чиксез шат, билгеле.

Р.Бикчәнтәев куйган бу музыкаль комедия күңелләрне күтәреп, туйганчы көлдереп, талантның, гаделлекнең, мәхәббәтнең җиңүен раслый торган мәдхия булып, ничә еллар тулы залларда зур уңыш белән барды. Әлбәттә, спектакльнең уңышы режиссер сайлаган артистларның осталыгында иде. Г.Камалова, Р.Бикчәнтәев, Г.Надрюков, Н.Гайнуллин, А.Харисова, Р.Әбелмәмбәтов (рухлары шат булсын), Наилә Гәрәева кебек танылган, талантлы артистлар ансамбле, алар тудырган җанлы, тулы канлы образлар беркемне дә битараф калдырмады. Шәмсия – Камалова иреннән аерылган, дәрте ташып торган, чәчләренә ефәк тасмалар тагып, тулы гәүдәсе белән кызларча кыланырга тырышкан, кияүгә чыгарга ашкынган, хәйләсе дә эчкерсез булган бер хатын иде. Музыкальлек, ритм, ни кыланса шуны аклый алырлык талантлы табигыйлек! Рольгә чуму, рольдә йөзү дип шушы уңайдан әйтергә буладыр. «Банкрот»та, мәсәлән (реж.П.Исәнбәт аны водевиль итеп сәхнәләштергән иде), шәп җырчы тавышы булмаса да, Гәүһәр апа Нәгыймә карчык ролендә куплетлар башкарып, алкышлар җыя иде (Ә ул бу куплетларны композитордан махсус сорап яздыра!)

● «Татар хатыны ниләр күрми». Сабира.

«Хуҗа Насретдин» (Гөлбану, Сәхилә), «Беренче мәхәббәт» (Камилә), «Зөбәйдә адәм баласы» (Мәрвәр), «Назлы кияү» (Гөлбану), «Татар хатыны ниләр күрми» (әрем тел Сабира), «Әни килде» (Зөләйха) кебек халык агылып йөргән спектакльләрнең уңышында Гәүһәр апаның үз казанышы бар иде. Образлары – бер-берсенә бөтенләй ошамаган, капма-каршы холыклы хатыннар: коточкыч явыз кайнана Сабира дисеңме, киң күңеллелеге, яхшылыгы белән үзенә тартып торган Зөләйха дисеңме – барысы да ышандыра, артистка үзе шундыйдыр дип уйларлык итә. Ул рус, чит ил әсәрләрендә дә әнә шулай табигый иде. Г.Камалова башкарган рольләр 100 гә якын. Кырык еллап сәхнәдә булды бит ул! Һәм заманында аны шул яраткан сәхнәсеннән, яраткан тамашачыларыннан аерырга теләүчеләр табыла. «Кыскарту» әмеренә кул куела. Ул йә башка театрга китәргә, йә режиссер ярдәмчесе урынында сәхнә артында гына торырга тиеш була... Ярый әле зур талантка өстәп, Аллаһ аңа көчле, көрәшче холкы да биргән. Яраткан әтисен дә, баласын да, сөекле ирен дә («ир бирмәк җан бирмәк» ди бит халык. Студент елларыннан ук бергә булып, яратып өйләнешкән ире артист Дэллюс Ильясов шул ук театрда башка гаилә кора) югалту ачысын татып шактый кырысланган, түзеп чыныгу алган Гәүһәр ханым бу көтелмәгән бәрелештән барыбер җиңүче булып чыга. Кирәк җирләргә яза, авыруга әйләнсә әйләнә (аны 68 яшендә шикәр авыруы алып китте), әмма табигать биргән талантны «кыскартырга» рөхсәт итми, ирек бирми! Әйе, ул көчле шәхес иде. Үзенең талантына, алай гына да түгел, талантлы нәселенә таянып эш итте. Кемгәдер ярарга тырышып, ялагайлануны кирәк тапмады. Туры сүзен курыкмыйча бәреп әйтте.Шул кемгәдер ошамагандыр да инде... Талантларга (бары тик талантлыларга!) һәр төрле шартлар тудырылырга, бар юллар да ачык булырга тиеш дип, гаделлеккә инанып яшәде... Бәлки бу Галиәсгар абзыйлардан килгән девиз, васыятьтер...

... Гәүһәр апаның турыдан-туры дәвамчылары булмаса да, камаллылар күп. Без барыбыз да камаллар династиясеннән!

Луара ШАКИРҖАН,
Татарстанның халык артисты.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

5 ноябрь (шимбә). ***Рабигул ахир аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 15.17 сәгатьтә калка, 3.58 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.58 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Томау интектерсә

Мондый эчемлек хроник фарингит һәм томаудан интегүчеләргә аеруча файдалы. 1,5 литр су кайнатып, суыталар, шунда 0,5 г аскорбин кислотасы, 1 аш кашыгы эре тоз эретәләр, 1 лимон согын кушалар. Якынча сәгать ярым эчендә вак йотымнар белән әкренләп эчеп бетерәләр, кайнар ваннада яки мунчада юыналар, аякка йон оебаш киеп, җылы юрган ябынып, йокларга яталар.

6 ноябрь (якшәмбе). ***Рабигул ахир аеның 12 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 15.24 сәгатьтә калка, 5.23 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.54 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Экземадан дәва

Банкага 1 йомырка сытып, өстенә акбур салалар һәм боткасыман хәлгә килгәнче яхшылап туглыйлар. Даруханәдә сатыла торган 1 чәй кашыгы дегет кушып, болгаталар, капкач ябып, караңгы урында 1 тәүлек тоткаталар. Йоклар алдыннан экземалы җирләргә сөртеп, өстеннән целлофан ябалар һәм җылы тукыма урыйлар. Кычыту беткәнче, җәрәхәтләр җөелгәнче шулай дәвалаланалар.

7 ноябрь (дүшәмбе). ***Рабигул ахир аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 15.32 сәгатьтә калка, 6.47 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.50 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик язын тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Суганлы су

Бабасырны бетерү өчен, 1 баш суган яки сарымсакны вак кына турап, 1 стакан салкын суга салалар, төнгелеккә калдыралар. Иртән сөзеп, ач карынга вак йотымнар белән эчеп бетерәләр.

8 ноябрь (сишәмбе). ***Рабигул ахир аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 15.42 сәгатьтә калка, 8.12 сәгатьтә бата. 14 сәгать 02 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 8.46 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Бавырны чистарту

0,5 кг мүк җиләге, 250 г сарымсак, кабыгы белән 2 лимонны иттарткычтан чыгарып, 400 г бал өстиләр, әйбәтләп болгаталар, суыткычта саклыйлар. Иртән һәм кичен 2 шәр чәй кашыгы кабалар. Дәва курсы – 1 ай.

9 ноябрь (чәршәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 15 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 15.56 сәгатьтә калка, 9.35 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.42 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Баллы лимон

Холециститтан болай дәваланалар. 4 лимонны иттарткычтан чыгарып, 1 кг бал, 200 г зәйтүн мае кушалар, агач кашык белән болгатып, суыткычта саклыйлар. Көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр аш кашыгы кабалар. Дәва курсы – берничә ай.

10 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 16 нчы көне.17 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 16.16 сәгатьтә калка, 10.51 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.38 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Чикләвек сихәте

Кан тамырлары киңәюен дәвалау өчен, 1 чәй кашыгы төелгән мөшкәт чикләвеген 1 стакан кайнар суда эретеп, 1 аш кашыгы бал өстиләр. Иртәнге ашка 1 сәгать кала һәм кичке аштан соң 2 сәгать үткәч, 1 әр стакан эчәләр.

11 ноябрь (җомга). ***Рабигүл ахир аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 16.45 сәгатьтә калка, 11.55 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.34 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Кишер торты

Эре угычта кырылган 2 стакан кишер, 4 йомырка, 1 стакан шикәр, 200 г атланмай, 3 стакан он, серкә белән сүндерелгән 1 чәй кашыгы сода кирәк. Атланмайны эретеп, шикәр, сода, йомырка кушып туглыйлар, он өстәп, камыр басалар. Майлы табага җәеп, газ мичендә пешерәләр. Икегә бүлеп, уртасына эремчекле йомшак сыр яки каймак, яисә варенье сылыйлар, өстенә шикәр оны сибәләр.

ТАРИХТАГЫ

● В.Данилов тырышлыгы белән торгызылган Тау ягы татар керәшеннәре музее ачылышы.

Безнең як – Тау ягы археологлар, тарихчы галимнәр тарафыннан шактый аз тикшерелгән. Ә бу як тарихи вакыйгаларга бик бай. Элек шушы як аша Нугай даругасы, Кырым даругасы, Урта Азиягә, Кавказга, Мәскәүгә юллар үткән. Мәскәү тарафыннан килгән баскыннар да Казанга шушы Тау ягыннан сузылган. Емельян Пугачёв, Степан Разин, Аксак Тимер походлары да шушы як аша узган. 1552 елда Явыз Иванның төп отрядлары да Казанны яуларга шул яктан килгән. Алар Муром шәһәреннән Алатырьга, аннан далалар буйлап Идел елгасыннан ерак булмаган Якле елгасына, Чынлы, Карлы, Бола, Бия елгалары аша Үтәк авылы болынына, аннары Зөя кирмәненә, ахыр чиктә Казанга юл тота. Тау ягы дәһшәтле, кырыс халыклардан торганга, андагы авылларның байтагы яшәү урыннарын да алыштырып торырга мәҗбүр булган. Аксак Тимернең Бөек Болгар дәүләтенә һөҗүм итү чорында Олы Чынлы, Олы Задур һ.б. авыллардан күчеп, Хуҗа Хәсән, Мәлки, Иске Кырбаш кебек авыллар оешкан.

Чукындыру чорында хәзерге Яшел Үзән районының Норлат ягындагы Әрә һәм Бува елгалары буендагы авыллардан, шул ук исәптән Тугай авылыннан да күп кешеләр яшеренеп, Яльчек ягында Иске Буа, Әрә (Байморза, Кыексар) авылларын оештыра. Хәзерге Кайбыч районы өлешеннән Яльчек-Буа каласы ягына качып, Яңа Чәчкаб, Кайбыч, Нурлат авыллары да барлыкка килә. Хәзерге Кайбыч районы территориясендәге Хуҗа Хәсән, Мәлки һәм Яңа Суринское авылларыннан качып киткән кешеләр Буа, Яльчек, Апас районнарында Кырбаш, Бикути, Кыр Тутае, Сүриле һәм Күкшәм авылларына нигез сала.

Кайсы Чүти беренче?

Бер үк исемле авылларның килеп чыгуы, аларның күп булуы православный миссионерларны, тарихчыларны, археологларны бик бутаган. Мәсәлән, Чүти исемле авылларның күп (4) булуы, аларның тиз арада һәм стихияле рәвештә оешуы күп миссионерларны һәм тарихчыларны да ялгыш юнәлешкә сөйрәгән. Чүти исемле авылларның иң олысы Иске Чүти – Чуваш Чүтие авылы, русча – Старое Чутеево. Бу авыл XVI гасырның икенче яртысында, Явыз Иван Казанны яулап алганнан соң, шул Казан ягыннан килгән һәм әлегәчә чукындырылмаган Чутей исемле чуваш морзасы тарафыннан оешкан. Бу авыл Чувашия республикасы составында, Татарстан чигендә, Хуҗа Хәсән авылыннан бер чакрым ераклыкта урнашкан, җирләре аз. Әлеге авылны кайбер тарихчылар ялгыш Яңа Чутей дип тә язып куйган. Икенче Чутей исемле авылны оештыручы шушы Иске Чүтине – Чуваш Чүтиен оештырган Чүти исемле чуваш малае Иванка була. Әтисе оештырган авылда җирләр җитмәү сәбәпле, Иванка өйләнгәннән соң үзенең дуслары белән бергәләшеп, яңа җирләр эзләп, Гөбенә елгасының уң ягына чыгып, куе урманнар уртасындагы аланлыкка килеп чыга. Алар анда Яңа Чүти исемле авыл оештыра. Гөбенә елгасының сул ягындагы болыннар, сөрү җирләре Хуҗа Хәсәнлеләрнеке булып саналган. Ә Яңа Чүти авылы, Иванка оештырган авыл җирләре, ул заманда буш булса да, дәүләтнеке саналган, резервта булган.

1612 елдан соң бу җирләр дәүләт тарафыннан бүләк итеп князь Пожарскийга бирелә. Пожарский бу җирләргә Ярославль, Кострома, Түбән Новгород якларыннан крепостной крестьяннар китерә. Авылның исеме алышына башлый. Аны әүвәл Яңа Чүти-Новое Чутеево дип йөртсәләр дә, урыслар килгәннән соң Чутеево – Чутей – дача Пожарского – дача Ильинского дип атап яза башлаганнар. Авыл бик тиз үсә, зурая, аның бер башы Гөбенә белән Тырма елгасы кушылган җиргә барып тоташа. Әкренләп авылны да Чутей – дача Ильинского – Турма – село Турминского дип үзгәртеп йөртә башлыйлар. Ә Иванка белән килгән чуашлар бу авылдан балаларын һәм туганнарын җыеп, күченеп китәргә мәҗбүр була. Алар Гөбенә елгасы буйлап тагын да югарырак китеп, елганың сул ягындагы аланлыкта тагын бер Яңа Чүти исемле чуаш авылы оештыра. Бу хәл XVII гасырның икенче яртысына туры килә. Ә 1760-1780 елларда бу урынга йомышлы татарларны Арзамас, Сергач, Темников якларыннан күчереп урнаштыра башлыйлар. Шулай итеп, чуаш авылы әкренләп татар-мишәр авылына әверелә башлый, ә авыл исеме искечә Чүти булып кала. Бу Чүти исемле өченче авыл булып санала. Чуашлар биредән көньякка, Яльчек ягына, Кушелга, Камышлы, Күлбашы авыллары янәшәсенә күченеп утыра. Ул авылга яңадан Новое Чутеево дип исем бирәләр. Монысы инде Чүти исемле дүртенче авыл була. 1950-1960 елларда Чувашстанның Яльчек районы бу авылны Пинеры исемле авыл җирлегендә берләштерә. Ә өченче Чүти авылын тарихчылар ялгышып Иске Чүти (Старое Чутеево) дип язып калдыра. Шул татар Чүтие авылын тирә-як авыл кешеләре Чүти-мишәр авылы дип йөртәләр. 1781-1782 елларда шушы авылда 28 җан чукындырылган татар һәм 68 җан йомышлы татар яшәгән. Ул елларда биредән чуашлар китеп беткән була. Анда йомышлы татарларны чукындырырга ярамаганын ишетеп, тирә-яктагы чукындырылган татарлар шушы мишәрләр канаты астына кереп котылырга тырыша һәм бу авылга яшерен рәвештә күченеп утыра. Авылның яшәү урынын да алыштырып, Гөбенә елгасының сул ягыннан уң ягына күченгәннәр. Шулай итеп буталчыклык та нәкъ шушы елларда ук башлангандыр. Чөнки Гөбенә елгасының сул ягындагы авыллар язылган Дәүләт китап битләре югалганын исәпкә алып, Иске Чутей авылы – Чуваш Чүтие авылы югарыда күрсәткән китапта булмавы сәбәпле, шул ук вакытта, Чутей мишәре Гөбенә елгасының уң ягындагы исемлеккә кереп калган. Татар Чүти халкы бик тиз үрчегән. 1834 елда бу авылда 451 җан йомышлы татар һәм 78 җан чукындырылган татар яшәгән. 1859 елда халык саны 1000 кешегә, 1907 елда 2683 кешегә җитә. Чукындырылган татарлар барысы да яңадан Исламга кайта. Сүз уңаеннан, безнең Платон исемле бер бабабыз яңадан Исламга кайтып нәсел калдырган. Андагы Галиәскәр бабай, аның нәселләре Әхмәтҗановлар, Гыйльфановлар – барысы да безнекеләр, калганнары Үзбәкстанда яши. Чүти авылы атаклы ат карагы – Шәкүр карак һәм язучы Зариф Бәшири авылы булып та тарихта кала.

Иске Буа авылы ник Иске Кырбаш?

Шундый ук буталчыклар хәзерге Мәлки авылы җирлегенә кергән Иске Кырбаш (Түбән Кырбаш) авылы белән бәйле. Ул Иске Кырбаш – Иске Буа авыллары белән бер чорда, XIV гасыр ахырында, XV гасыр башында ук оешкан була. Оештыручысы Хәсән белән Мәликнең бертуган энесе Кырганбаш булган, дип халык телендә калган. Шушы Иске Кырбаш халык телендә Түбән Кырбаш дип тә атала, чөнки ул Ырым елгасы белән Гөбенә елгасы арасында, түбәнлек җирдә урнашкан. Иске Кырбаш – Түбән Кырбаш Хуҗа Хәсән волосте Свияжск өязе составында, ә 1750 елдан соң Хуҗа Хәсән волосте Чуел (Цивиль) өязе составына кергән. Мәлки авылы белән Иске Кырбаш авылларын Ырым елгасы гына аерып тора, алар Гөбенә елгасының сул ягында урнашкан. Иске Кырбаш-Түбән Кырбашта 1929 елга кадәр авыл Советы, ә 1950 елга кадәр Сталин исемендәге колхоз да булган. Хәзер бу авыл географик яктан Мәлки авылы белән тулысынча тоташкан һәм аның составына кергән.

Шулай ук элек Тәтеш өязендәге Иске Буа авылын да, нигәдер Совет чорына кадәр кайбер дәүләт һәм чиркәү документларында Иске Кырбаш дип язып калдырганнар. Моны да аңлап булмый. Халыкта йөргән сүзләрдән билгеле булганча, Иске Буа, яңа Буа (Кыр Буасы), Әрә – Байморза – Кыексар авылларын хәзерге Бува елгалары буеннан күченеп килгән кешеләр оештырган. Айдар авылы янындагы Тугай исемле авылны да урындагы халык Әрә авылы да дип йөртә. Бәлки, Иске Буа авылын әүвәлге документларда Иске Кырбаш дип аталуының сәбәбе түбәндәгеләр түгел микән?

Беренчедән, XIV-XV гасырда ук Хәсән белән Мәликнең бертуганы Кырганбаш күченеп, безнең якка килеп урнашканда, бу төркемнең бер өлеше Кырганбаш җитәкчелегендә Гөбенә елгасының сул ягында калып, бер авыл (Иске Кырбаш – Түбән Кырбаш) оештырса, икенче өлеше җир җитмәү сәбәпле, Гөбенә елгасының уң ягына чыгып, тагын бер Иске Кырбаш исемле авыл оештыргандыр, дигән фараз туа. Соңрак шушы авыл янына хәзерге Яшел Үзән районындагы Норлат зонасыннан – Бува (Буа) елгасы буеннан качып килгән икенче бер төркем халык шушы Иске Кырбаш авылына кушылып, авылның исемен Иске Буа дип атаулары да мөмкин. Монысы дәреслеккә охшый.

ЯЛГЫШЛАР



●1710 елгы халык санын алу язмаларында Хуҗа Хәсән турында бер сәхифә.

Чөнки Кайбыч районындагы күрше Байморза, Әрә авыллары исемнәре дә шуннан килгәнлеге билгеле.

Хуҗа Хәсән авылы ник Күкшәм?

Иң зур тарихи буталчык Хуҗа Хәсән авылының язмышына бәйләнгән. Монда сүз авылның кайчан оешуы һәм 100 елга якын Хуҗа Хәсәннең волость үзәге булып торуы турында бара. Ни өчендер тарихчылар 37 ир-ат яшәгән кечкенә генә Хуҗа Хәсән дигән хуторны, зур 250 кеше яшәгән Хуҗа Хәсән авылыннан аера алмаганнар икән? Волость идарәсе 250 кеше яшәгән Хуҗа Хәсән авылында 100 елга якын хөкем сөрә бит югыйсә. Ә 37 ир кеше яшәгән Хуҗа Хәсән хуторы кешеләре көчләп чукындыру чорында, 1730-1740 елларда Апас районы җирлегендә Хозесаново-Күкшәм авылын оештыра һәм Урта Балтай волосте составына керә. Шушы фактларны белмичә, ничек итеп тарих язып булсын?

Икенче ялгышлык авылыбызның оешкан еллары турында. Татарстан авыллары энциклопедиясендә Хуҗа Хәсән авылы XVII гасырда оешкан дип язганнар. Тарихтагы мәгълүмат нигезендә безнең Хуҗа Хәсән авылында 1647-1649 елларда урыс кенәзе Шиховской булып киткән. Ул үзенең усадьбасын ясар өчен буш җирләр эзләп йөргән. Авылда җыелыш вакытында бер чуашны да үтергән булганнар. Тарихчылар архивларда безнең як, шул исәптән безнең авыл буенча да башка мәгълүматлар таба алмаганнардыр. Чөнки 1565 һәм 1597 елларда авылларны исәпкә алу китабында Ногай даругасы буендагы Гәбенә елгасының сул ягындагы авыллар язылган китап битләре югалган. Моның турында китапта язылган аңлатма да бар. Югалган битләрдә Чуваш Чүтие – Иске Чүти, Хуҗа Хәсән, Мәлки, Иске Кырбаш, Зур Тәрбит, Янсуринск, Иске Тәрбит һәм тагын 10лап авылларның исемлеге дә юкка чыккан. Тарихчылар бу китаптагы аңлатманы укып та карамаган, ахры. Әйтеп киткән авылларның оешу чорлары XIV гасырдан XVII гасырга тикле сузылган. Халык теләндә буыннан-буынга күчеп килгән сөйләмнәр буенча, Хуҗа Хәсән, Мәлки һәм Иске Кырбаш авыллары XIV гасыр ахырында, XV гасыр башында ук оешкан. Бу авылларны өч бертуган – Хәсән, Мәлик, Кырганбаш (Корбанбаш) нигезләгән. Алар Чистай ягыннан килгән. Моны исбатлау өчен, мин авылдашым Аркадий Демьянович Черемисов белән 2018 елда Казан тарих институты аша ДНКларны Мәскәүнең генеалогия лабораториясенә анализ ясар өчен тапшырган идем. Нәтиҗәдә институт мондый җавап бирде: «Уроженцы села Хозесаново – Данилов Вячеслав Власович и Черемисов Аркадий Демьянович, у которых взяты пробы, что эти люди относятся к гаплогруппе R1a1 – основной гаплогруппе татар. Она идет от древних булгар. Они ближайшие совпаденцы для друг друга. Их общий предок жил порядка 400-600 лет назад. Удаленные 600-800 лет назад. Они переселенцы из деревень Большая Цильна и Большая Задорновка (Задур авылы)».

Димәк, 1392-1400 елларда Аксак Тимер Бөек Болгар дәүләтен җимергән, яндырган чорларда Олы Чынлы белән Олы Задур авылларының берничә төркеме Хәсән, Мәлик һәм Кырганбаш җитәкчелегендә авылларыннан качып киткән. Башта, мөгаен, Идел елгасының Шәһри Болгар ягына чыкканнардыр, ә дошман Иделне кичкәч, алар инде Чистай ягына юнәлгән, соңрак Чулман аша Казан ягына житеп, яңадан Иделне кичеп, хәзерге урыннарында авылларын оештырганнар булып чыга. Мәскәү лабораториясенең анализ нәтиҗәләре тулысы белән бу сүзләрне исбатлый. Шулай итеп, шушы 3 авыл – Хуҗа Хәсән, Мәлки һәм Иске Кырбаш XIV-XV гасырларда ук оешкан дип нәтиҗә ясарга тулы хакыбыз бар.

Ә Хуҗа Хәсән авылының 100 елга якын волость үзәге булуы турында берничә җөмлә өстик. Гәбенә елгасы буендагы Хуҗа Хәсән авылы кешеләре 1744 елда чукындырылганнан соң, урнашкан урыннан кузгалып, Буа, Сембер ягына юнәлгән. Элек яшәгән җирләреннән 50 чакрым ара үткәч, урманда аланлыкка килеп чыгалар. Шунда җитәкчесе, күктәге айны күреп, «әйдәгез, егетләр, күк – шәм кебек, шушында урнашыйк әле», дигән. Шулай итеп, авылның исеме дә Күкшәм дип атала.

В.ДАНИЛОВ,
Татарстанның атказанган икътисадчысы.

РЕДАКЦИЯДӘН: Газетабызның даими укучысы, Татарстанның Тау ягы төбәге тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән Вячеслав Власович Данилов берничә көн элек 85 яшьлеген каршы алды. Аны олуг гомер бәйрәме белән котлап, ныклы сәламәтлек, тыныч тормыш, гаилә бәхете, халкыбызга кирәкле хезмәттә бетмәс-төкәнмәс энергия телибез.

тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

4,5,6 ноябрь – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
10 ноябрь – Зур залда – Слава Полунинның Кар шоуы. Кече залда – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).
11 ноябрь – Зур залда – Слава Полунинның Кар шоуы. Кече залда – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

5 ноябрь – «Шүрәле» (Ф.Яруллин).
6 ноябрь – StagePlatforma фестивале кысаларында заманча балет кичәсе.
7 ноябрь – StagePlatforma фестиваленең гала-концерты.

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

4 ноябрь – «Кияүләр» (Х.Вахит).
5 ноябрь – 12.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
6 ноябрь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре. Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
8 ноябрь – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
9 ноябрь – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
10 ноябрь – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).
11 ноябрь – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

4 ноябрь – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).
5 ноябрь – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская), 18.00 – «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).
6 ноябрь – «Ак чәчәкләр кебек» (Р.Мухина).
8 ноябрь – «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

4 ноябрь – Зур залда – «Новые приключения трех поросят» (Б.Вайнер). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
5 ноябрь – Зур залда – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин). Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
6 ноябрь – Фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков). Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
8 ноябрь – «Shurale: яңа фантазия» (Ф.Яруллин).
10 ноябрь – «Буратино» (А.Толстой).
11 ноябрь – «Буратино» (А.Толстой).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

